*Ленар* ***Шәех***

ДҮРТЕНЧЕ КАТ... БИШЕНЧЕ КАТ...

*Шигырьләр, поэма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш11

**Шәех Л.М.**

Дүртенче кат... Бишенче кат...: шигырьләр, поэма / Ленар Шәех; кереш сүз авт.: Р.Миңнуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.— 176 б.— 2000 д.
ISBN 978-5-298-01697-1

Яшь шагыйрьнең лирикасы кайчак сагышлы, гамьле, берара шаян, якты. Ә юморы, сатирасы үткен, төрттерүле. Аның поэма, цикллары да игътибарны җәлеп итә. Шагыйрь укучыларын үз дөньясына чакыра...

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
ISBN 978-5-298-01697-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Шәех Л.М., 2008

## Шигърияткә Ленар Шәех кирәк!

Безнең татар шигъриятенә күптән инде Ленар Шәех кебек бер егет кирәк иде.

Менә ул килде. Яшенә карата шактый зур багаж белән. Әдәбиятка җитди караучы, өлгергән өлгер шагыйрь булып, чын әдәбият кешесе булып. Аның соңгы еллардагы һәм әдәби, һәм иҗтимагый эшчәнлеге мине бик тә куандыра һәм олы өметләр уята.

Ул үзенең беренче әдәби чыныгуларын безнең «Сабантуй» гәзитендә алган иде. Бәхете дә бар икән: әдәбият бүлеген җитәкләгән халык шагыйре Илдар абый Юзеев аның тәүге шигырьләренә үк игътибар итте. Гомере буе иҗат яшьләре белән эшләгән Илдар абыйның аталарча ихлас ярдәме, киңәшләре, фикерләре Ленарны олы шигърияткә алып керде. Аның язганнарының барысы да диярлек Остазның таләпчән кулы, шигъри күңеле аша узды. Остаз мәктәбен узган шәкерттән без күпне көтәргә хаклы.

Яшь булуына да карамастан, Ленар берничә китап та чыгарырга өлгерде. Өлкәннәр өчен дә, балаларга атап та. Шигырьләре, әйтер идем, төрледән-төрле: формалары да, тематикасы да, тел-стиль үзенчәлекләре дә... Образлылык ягыннан да, жанр нисбәтеннән дә үз-үзен кабатламаска тырыша. Балалар шигъриятендәге эзләнүләре дә кызыклы гына. Эзләнүләре бушка китмәс, киләчәктә үзенеке генә булган ачышларга да китерер дип өметләнәм. Аның мәхәббәт шигырьләренә дә еш кына нечкә шаянлык-наянлык, үткен сүз уйнатулар килеп керә. Ул үзенең сагышлы, моңсу хисләрен дә нечкә юморга төреп бирә белә. Монысы да — шигырьләрен бизи торган матур сыйфат.

Мин аны, әлбәттә инде, үзен ахыргача тапкан шагыйрь дип әйтәсем килми. Әлегә эшләнеп бетмәгән, ачкычы табылмаган көпшәк, йомшак шигырьләре дә очрый. Моңа бер дә гаҗәпләнәсе юк: тавык та бит кыткылдаган саен алтын йомырка салмый. Яшерен-батырын түгел, шигъри хилафлыклар классикларда да тулып ята. Ә камиллекнең аның чиге булмый, эзләнүләр, табулар, югалтулар гомер буена дәвам итә. Әмма Ленарның үҗәтлеге, тырышлыгы, эшчәнлеге хупланырга тиеш. Ул бит әле бик актив эшләүче җитди журналист та. Аның язмалары укучыларны үзенә җәлеп итә, бәхәсләр уята... Һәрхәлдә, битараф калдырмый. Чөнки ул үз сүзен әйтә белә, үткәрерлек итеп яза белә.

Аннары, Ленар үз чордашлары арасында бик тә популяр, абруйлы кеше. «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенең җитәкчесе, «Тәрәзә» гәзитенең баш мөхәррире, төрле конкурслар, фестивальләр оештыручы, Башкортстандагы иҗат яшьләре белән элемтәләр урнаштыручы... Үз каләмдәшләренең лидеры булу аның абруен тагын да арттырып җибәрә.

Әгәр дә Ходай кушса, шуның өстенә үзе дә җиң сызганып, бөтен сәләтен җигеп армый-талмый эшләсә, Ленар татар шигъриятенең танылган бер шәехе булыр. Һәрхәлдә, мин аның шулай булуын телим. Безнең шигърияттә бәдәвиләр болай да җитәрлек...

Иманым камил, минем әле язганнарыма Остазыбыз Илдар абый Юзеев үзе дә һич икеләнмичә кул куяр иде.

*Роберт Миңнуллин*
Татарстан Республикасының
халык шагыйре

## Әгәр син янымда булсаң...

Мәхәббәтең — йомшак җилкәй,
Тулган ай күк күзләрең.
Елмаюың — май кояшы,
Таң җырлары — сүзләрең.

Хыялларың әкияти,
Ак кардай синең күңел.
Адымнарың шундый җиңел —
Туктатырлык та түгел.

Корабка җилкән булырмын,
Коштай күккә менәрмен.
Теләсәң, җаным бирермен,
Синең өчен сүнәрмен.

Мин сихри таяк булырмын,
Судагы алтын балык.
Очарга да өйрәнермен,
Сине кулыңнан алып.

Елга булып агармын мин,
Ярларымнан ташармын.
Әгәр син янымда булсаң,
Җиде күккә ашармын.

## Өч сүз

Тактага өч сүз язылган,
Серле һәм назлы итеп.
Язган кеше утырадыр
Офыктан кояш көтеп.

Акбур белән язылса да
Җирдәй кара тактага,
Шул сүзләрне укый-укый,
Йөрәк тынгысыз кага.

Күпме хис һәм күпме сөю
Салынган бу җөмләгә.
Әйтерсең мин бу сүзләрне
Моңа кадәр күрмәгән?

Әйтерсең мин беркайчан да
Мәхәббәттә янмаган.
Уйны
сөю шәрабына
Гүя бер дә манмаган.

Кемгә генә аталган соң
Ихлас хисләр агышы?
Күңелемне биләп ала
Сер һәм тылсым сагышы.

Исем китеп карап торам:
Кем бу сүзләрне белми? —
«Мин сине яратам»,— дигән
Әллә чын, әллә юри?..

* * *

Сине күргән саен җанда
Бер шигырь бөреләнә.
Тамчы гына булган шатлык
Зурая, эреләнә.

Җилкәмнән тау төшеп китә,
Каурыйдай җиңеләям.
Кысыла бөтен көченә,
Тартыла күңел җәям.

Шул чагында, кош шикелле,
Эх, бер очасы килә.
Сөю тулы яшьләремә
Нидер кушасы килә...

...Сине күргән саен җанда
Бер чәчәк бәреп чыга.
Гөлчәчәкләргә төренеп
Шигырь ияреп чыга.

* * *

«Ян, йолдызым, ян!» —
дисең син,
Янмыйча карале син.
Сөйгәнең йолдыз сораса,
Алмыйча карале син!..

## Мәхәббәт

Мәхәббәт — күземнең карасы,
Мәхәббәт — йөрәгем ярасы,
Яндырдың, көйдердең, көл иттең —
Юкмы һич дәвалау чарасы?

Мәхәббәт — иң гүзәл яз гөле,
Мәхәббәт — дөньяда иң тере,
Мәңгегә картаймас һәм сулмас,
Мәхәббәт — күңелдә яшь бөре.

Мәхәббәт — кояшның яктысы,
Мәхәббәт — дөньяның ак төсе,
Мәхәббәт — пакь айның чаткысы,
Мәхәббәт — дөньяның ак көче.

Мәхәббәт — болытлар агышы,
Мәхәббәт — чишмәләр чабышы,
Мәхәббәт — буш кырлар сагышы,
Аккошның канатын кагышы.

Мәхәббәт — елгалар ташуы,
Мәхәббәт — хисләрнең шашуы,

Хыялның тормышка ашуы,
Күңелнең тынгысыз ярсуы.

Мәхәббәт — талгын җил иркәсе,
Мәхәббәт — җәйге көн иртәсе...
Килми бит сөйгәнне калдырып
Чит җиргә китәсе, китәсе...

## Мин яратам...

*(Эрнет Гинсберг буенча)*

Мин яратам, ә син — юк,
Мин — болытмын, ә син — күк.
Күңелемдә моң да зар,
Килмәстер бәхет-мазар.

Син мине күрмисең дә,
Тик минем гел исемдә:
Бәхетлесең, бу бик хуп —
Мин яратам, ә син — юк.

## Каян дөньяга килгән без?

*(И.В.Гётега ияреп...)*

Каян дөньяга килгән без? —
Сөюдән.
Тормыш сынавын җиңгәнбез? —
Сөюдән.
Нәрсәдән соң адашкан без? —
Сөюдән.
Җиде күкләргә ашкан без? —
Сөюдән.
Күзләр мөлдерәмә тулы?..—
Сөюләр...
Тап үзеңнең бәхетеңне,
И юләр!..

## Нокта яки... өтер?..

Күз алдыңа китер:
Нокта яки өтер,
Өтер яки нокта,
Алга ыргыл! Тукта!

Күз алдыңа китер:
Тормышыңа өтер,
Тормышыңа нокта —
Уйлан! Атла! Тукта!

Мәхәббәткә нокта,
Мәхәббәткә өтер,
Күз алдыңа китер:
Өтер, өтер, өтер...
Калганнары — «туфта»!

* * *

Татлы сагышым,
Серле табышым.
Әллә язмышым?..
Әллә ялгышым?..

Өнемме?.. Төшем?..
Хөрмә җимешем,
Минем өлешкә
Тигән көмешем.

Бөтен халәтем,
Барлык хәятым,
Син — бердәнберем,
Син — мәхәббәтем.

* * *

Минем күңелем — суыткыч,
Хисне туңдырып саклыйм.
Яраларымны ямарга
Ак кардан ак җеп саплыйм...

* * *

Синең күзләреңне күрсәм,
коелам да төшәм.
Уй чуала. Баскан җирем
идән әллә түшәм.

Тирә-юньгә, төнгә-көнгә
исем китми бер дә.
Иң саф сөю хисләремне
йөрәгеңә эрлә...

Һәйкәл кебек басып торам,
эндәшми бер сүз дә.
Әллә нинди сихер, тылсым
бар күк синең күздә.

...Эримен дә бетәм инде,
әйтерсең лә мин — шәм...
Күзләремә бер карасаң,
коелам да төшәм.

* * *

Ап-ак бәхетләр килмәс —
Күңелемдә сары бәс...

## Әгәр чынлап яратмасаң...

Әгәр мине яратмасаң,
Төшемә дә кермәс идең.
Шатланып һәм канатланып,
Янымда да йөрмәс идең.

Әгәр чынлап яратмасаң,
Кулың бирер идеңмени?..
Эшең ташлап, җил-җил атлап,
Янга килер идеңмени?..

Әгәр мине яратмасаң,
Күзгә туры бакмас идең.
Күңелеңнең иң түрендә
Наз елгасы акмас иде.

Әгәр чынлап яратмасаң,
Мине кочар идеңмени?..
Сөйләшкәндә сүзләреңә
Сөю кушар идеңмени?..

Әгәр мине яратмасаң...
Әгәр чынлап яратмасаң...

## * * *

Күзләреңә карарга да
Кыялмыйм —
Әллә нинди оялчан мин,
Хыялый.

Сөю тулы карашымны
Тыялмыйм,
Мәхәббәтле күзләреңнән
Туялмыйм...

Яннан узсаң, уйларымны
Җыялмыйм...
Төштә генә никтер синнән
Оялмыйм.

## Соңгы алма

Шүрләп куям салкын кышларыннан,
Кызыл алма төште учларымнан —
Тәгәрәде ап-ак карлар буйлап,
Боз каплаган ап-ак ярлар буйлап...

...Кайнар алма барда учларымда
Шундый рәхәт иде кышларын да!..
...Син бердәнбер соңгы алмам инде,
Мин бүтәнне яраталмам инде...

## Бары бер кат...

Дөньяда бәхет мизгелен
Бары бер кат кичердем.
Бар халәтем белән тойдым,
Гомерлеккә исердем.

Күзләреңә бары бер кат,
Бары бер кат багалдым.
Тирән сихер дәрьясында
Шул бәхетне табалдым.

Бары бер кат кулларыңны
Йөрәгемә алалдым.
Күктән көлгән ай шикелле
Кызардым да агардым.

Бары бер кат иреннәрем:
— «Сөям...» —
дип пышылдады.
Син генә хис дулкынына
Нигәдер кушылмадың...

Дөньяда бәхет мизгелен
Бары бер кат кичердем.
Ак томаннарга уралдың,
Эредең, очтың, югалдың...—
Мин мәңгегә исердем.

*** * ***

Син — якын-тирәдә,
Мин — күрше бүлмәдә.
Арада ялгызы
Йөрәгем тирбәлә.

*** * ***

Күңелләрем мөлдерәмә тулы,
Мөлдерәмә тулы күңелләрем.
Гамь көнендә гамь кояшы төшкәч,
Яшем түгелмәде.

Мөлдерәмә тулы күңелләрем,
Күңелләрем мөлдерәмә тулы.
Сары киңлек уртасында балкый
Кара басу юлы.

Күңелләрем мөлдерәмә тулы,
Мөлдерәмә тулы күңелләрем.
Ак бәхетләр янда гына йөргән —
Шуны да белмәдем.

Мөлдерәмә тулы күңелләрем,
Күңелләрем мөлдерәмә тулы.
Юлдан сабыр гына атлап киләм
Көтеп яратуны.

* * *

Гамьсез яфрак буйлап тәгәрәгән тамчы кебек
Мин яратам сине...

Тын елганы назлап кыбырсыткан җилкәй кебек
Мин яратам сине...

Карурманга үтеп кергән кояш нуры кебек
Мин яратам сине...

Буш түтәлдә шытып чыккан ялгыз гөлкәй кебек
Мин яратам сине...

* * *

Мин бәхеттән үлдем...
Чәчәк өстендә тынган күбәләк кебек.

Мин сөенеп үлдем...
Туган җиренә ятып сүнгән кош кебек.

Мин шатлыктан үлдем...
Яфрактан тамып, җиргә сеңгән чык кебек.

Мин сөелеп үлдем...
Иренеңдә эрегән бөртек кар кебек...

* * *

Йолдызларга сөйләр идем
сөюемне.
Алар әйтер: «Юләрләндем
диюеңме?..»

Куш каенга бәян итсәм
синең хакта,
Әйтмәсме ул, дәшмәсме ул:
«Сөю — хата...»

...Тургайлар да юатмасмы:
«Сөяр...» — диеп,
Әллә әйтер: «Акылыңа
ияр...» — диеп?..

Хөр җилләргә җиткералсам,
«Яратам...» — дип,
Әйтмәсме соң: «Ай күрә дә,
ала таң...» — дип?..

Аккошларга сөйләп бирсәм,
алар әйтер:
«Утка кердең, кем хәлеңне
җиңеләйтер?..»

* * *

Сары сагышлар сардылар,
Саргаеп үләм, ахры.
Исемең — гамьнән йолучы
Бердәнбер сүрәм, ахры.

## Миңа үзең кирәк...

Күзләремә кара —
Анда синең сурәт,
Ерак түгел ара —
Җанда синең сурәт.

Күңелемә күз сал —
Анда синең рәсем.
Хыялымда да син,
Учларымда — яшем...

Үткәнемдә дә син,
Бүгенгемдә дә син...
Ул сурәткә, белмим,
Нәрсә диеп дәшим?..

Рәсем, салкын рәсем...
Нәрсә бирә сурәт?..
Аңларсыңмы? Юкмы?..—
Миңа үзең кирәк...

* * *

Төн саен ачып керәсең
Ак төшләремнең келәсен.

* * *

Сәбәп тә кирәк түгел,
Шәраб та кирәк түгел.
Син үзең исертәсең,
Җанга хөр хис кертәсең.

Илһам да кирәк түгел,
Җиһан да кирәк түгел.
Син үзең дә җитәсең,
Коясың күңел бәсен.

Якты да кирәк түгел,
Чаткы да кирәк түгел.
Үзең — нур чыганагы,
Яктылык ерганагы.

Йолдызлар... кирәк түгел,
Бар кызлар... кирәк түгел.
Син — кояшым, аем да,
Син — күңел сараемда!

## Яз җыры

Сөюгә сусаган күңелгә
Ташкындай саф хисләр түгелә.
Серле көч бар сыман,
Йөрәк тә ярсыган,
Бар хәят гөл-назга күмелә.

Мәхәббәт язларга төренгән,
Кыш буе тилмереп йөрелгән.
Җанымда әллә ни,
Әллә-ли, бәллә-ли —
Мәхәббәттер инде. Кем белгән?..

## * * *

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Көнем моңсу, төнем караңгы.
Күңел яшем учка тамган чакта,
Кем дәвалар йөрәк ярамны?

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Җанда сагыш-гамьнәр өеме.
Ак болытлар күмгән ак офыкта
Билгесезлек, томан төене.

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Үзем генә беләм хәлемне.
Юлларыма килеп чыгарсыңмы,
Иңгә салып бәхет шәлеңне?..

## * * *

Сүрелдем, оныттым,
Сусаудан тилмергән
Хисләрне корыттым.

Күрәм ак болытны:
«Онытты... Онытты...» —
Кем җиңде, кем отты?..

## Күңелкәең китмәсме ереп...

Сөюемә башта ышанмадың,
Сер бирмәдең, килеп бушанмадың.
Мин генә тик йөрдем тилмереп —
Күңелкәең китмәсме ереп...

Күктән Җиргә очкан кометадай,

Озоннарда яндым мин ничә ай.
Йөрдем чирләп, кабат терелеп —
Күңелкәең китмәсме эреп...

Салкын яңгыр асты — минем ышык,
Эх, ярату — гамьле-татлы гыйшык!..
Өмет йөрде җаныма кереп —
Күңелкәең китмәсме эреп...

Көзге җилдә яфрак шавы булыйм,
Көмеш кышның ак кар тавы булыйм...
...Читтән генә карыйм үрелеп —
Бетмәгәнме күңелең эреп...

## Гыйнвар бураннары

*(Җыр)*

Ялгыз гына йөрим бүген
Казан урамнарында,
Кочагымны ачыйм әле
Гыйнвар бураннарына!

Кушымта:
Әйдә, гыйнвар бураннары
Күңелне урасыннар,
Сагышлы дип тормасыннар,
Ак бәхет юрасыннар!

Син җанны иркәләмәгәч,
Басмагач ярсуымны,
Бураннарга назлануым —
Үземнән качуыммы?..

Кушымта.

Казан урамында йөрим,
Буран мине очыртсын.
Җылы кочагыма кереп,
Язгы җил булып чыксын!

Кушымта.

## Синңа охшаган

Мин сине көтәм,
Никтер килмисең.
Сәгатем, үртәп,
Нигә көйлисең?..

Кая син, кая,
Әй тилмертүчем?..
Җылы сүз белән
Җанны эртүчем?..

...Күкләр катында
Оча бер тургай.
Качкан кояшны
Ул көтә бугай.

Ә теге шаян,
Чыкмыйча һаман,
Тилмертә бугай,
Көттерә бугай,
Кошның уйларын
Үз тирәсендә
Йөрттерә бугай...

...Әй, кояш-шаян —
Синңа охшаган.

## Имәнкискә кызына Такталачык егетеннән ачык хат

Күп баш ваттым бу хакта:
Син — Имән, ә мин — Такта,
Бик кызык бит, чынлап та.

Күреп торам ап-ачык:
Син — Кискә, мин — Алачык,
Йөрим шулай фал ачып.

Уңда, сулда гел урман...
Мин — Агыйдел, син — Чулман,
Икесе дә бер юлдан.

Уйланам, панимаешь,
Мин — Актаныш, син — Лаеш,
Кояш чыгыш һәм баеш...

Тактасы да кирәкле,
Имәне дә кирәкле —
Булыйк тырма-көрәкле!..

Әйтәм ачыктан-ачык:
Булсын Имәналачык,
Исең китмәсен һич тә —
Булсын, шәт, Тактакискә!

...Йөзгә җылы җил бәрә...
*И.* кызына *Т.* егете
Кайнар сәлам җибәрә.

## * * *

*(Үткәнгә карап язылган шигырь)*

Ходайга табынам диеп,
Мин сиңа табынганмын.
Инде сүндем, беттем дигәч,
Яңадан кабынганмын.

Тормышны яратам диеп,
Мин сине яратканмын.
Сүрелеп барган хисләрне
Кабаттан яңартканмын.

Фани дөньяда яшим дип,
Хыялда яшәгәнмен.
Газаплы бәхеттән генә

Берни эндәшмәгәнмен.

Өнемдә дә, төшемдә дә
Мин сине эзләгәнмен.
Син — минем язмышым икән,
Үзем дә сизмәгәнмен.

## * * *

Син һаман миннән көләсең,
Сөю — шаяру дисеңме?.. —
Кызган тимер белән яздым
Җаныма синең исемне.

## Айсылукай

*(Җыр)*

Исемеңнең яктысыннан
Сулган гөл дә терелә.
«Айсылу!» — дип язып куйдым
Күңелемнең түренә.

Кушымта:

Айсылукай!
Ай, сылукай!
Күңелемнең түрендә.
Йолдыз алыйм,
Утта яныйм
Ай караган төнемдә.

Күңелеңнең яктысыннан
Җаным күккә үрелә.
«Айсылу!» — дип уеп куйдым
Йөрәгемнең түренә.

Кушымта:

Айсылукай!
Ай, сылукай!
Йөрәгемнең түрендә.
Җилкәй булыйм,
Бәхет юрыйм
Сиңа сөю үрендә.

Исемеңнең яктысыннан
Дөньям нурга күмелә.
«Айсылу!» — дип язган Ходай
Язмышым, гомеремә.

Кушымта:

Айсылукай!
Ай, сылукай!
Язмышым, гомерем дә.
Син — үткәнем,
Син — көткәнем,
Син — киләчәк көнем дә.

* * *

Болай булмас чүлдә дә...
Җәйге эссе челләдә
Туңдырма ашый кызлар.
Йөрәгем ярсый, кызлар!..

Йөрәгем ярсулары!..
Әйтерсең кар сулары —
Басмас туңдырма гына.
Җанга кундырма гына
Туңдырманың туңнарын.
Тыңла йөрәк моңнарын,
Күңел кылы чыңнарын...

Җәйге эссе челләдә
Язлар белән чирлә дә,
Ничек тик ятмак кирәк?!
Ярсып сикерә йөрәк...

...Туңдырма ашый кызлар.
Йөрәгем ярсый, кызлар!..
Басмас туңдырма гына...
Басмас туңдырма гына...

* * *

Мин бит сине тормыштан да
ныграк яратам.
Йөрәгемдәге ярамны
тагын канатам.

Мин бит сине шигырьдән дә
ныграк сөямен.
Синең янда гына тоям
чын шигырь тәмен.

Син бит миңа гомеремнән дә
ныграк кадерле.
Йөрәгемне өзеп бирәм,
алчы, ал инде...

## Кызыл алма...

Кызыл алма кулларыңда —
Кайнар кояш шикелле.
Шул алмаңны миңа суздың —
Йөрәк шашып сикерде.

Елмаясың да көләсең,
Син язның үзе кебек.
Кызыл алмаң, серле алмаң
Күңелең күзе кебек.

Кулларыңда кызыл алма —
Ул синең ут-йөрәктер.
Тулы бәхет өчен минем
Йөрәк кенә кирәктер.

## Туган көн вальсы

*(Җыр)*

Августның йолдызлы күгендә
Серле ай нурларын сипкәндә,
Еракта, галәмнең төбендә,
Куш йөрәк тилереп типкәндә.

Кушымта:
Син тугансың, иркәм,
Һәммәсе шат икән,
Дөнья нурга манчылган.
Бәхетле барсы да,
Тыныч та, ярсу да —
Күк капусы ачылган.

Җимешле бакчалар түрендә
Алмалар тулышып пешкәндә,
Августның кояшлы көнендә
Көяз көз дөньяга күчкәндә.

Кушымта.

Урамда җиләс җил искәндә,
Елгалар моңланып акканда,
Төн Киек Каз Юлын кичкәндә,
Диңгезгә йолдызлар атканда.

Кушымта.

## Гашыйк

Иләсләнеп йөри болында,
Ромашкалар аның кулында.
Үзе җырлый... Әллә... елыймы?..
Күккә карап нидер сорыймы?..

«Ромашкалар сөя идең бит,
«Мин яратам!» — дия идең бит...
Өзгәч, корый таҗлы гөлләрем —
Нигә, тормыш, газап теләдең?..»

Анда бара, монда бәрелә,
Эзләреннән нур күтәрелә.
Каян килгән?.. Нигә?.. Адашкан?..
Әллә инде акылдан шашкан?..

«Бу болында безнең эзләр бар,
Чәчәкләрдә синең күзләр бар.
Тик тоялмыйм гөлләр җылысын —
Нигә, тормыш, һаман сыныйсың?..»

Ромашкалар җыйган бер кочак,
Зәңгәр күктә кызу ут-учак...
Берәү йөри гөлле болында,
Ромашкалар аның кулында:

«Сары көздә сары сагыш бар,
Ак таҗларда бәхет, язмыш бар.

Ромашкалар җыеп юанам,
Сагышымнан кайчан уянам?»

## * * *

Карлар ява инде, ап-ак карлар
Без таптаган юллар өстенә.
Пар каплаган тәрәз. Янәшәдә
Моңлы гына итеп көз көлә.

Карлар ява инде, ап-ак карлар,
Моңсу күкне тоташ томалап.
Юлны сарган сары яфраклардан
Көз елмая җанны юмалап.

Карлар ява инде, ап-ак карлар
Бергә салган эзләр өстенә.
Кар ята да эреп юкка чыга...
Саубуллашып тышта көз көлә.

## Җибәрмим

Син генә, син генә
уемда.
Син миннән китәргә
җыенма.

Сөюдән тилергән
җүләр мин.
Беркая, беркая
җибәрмим!

## * * *

Зәңгәр күкнең упкын-дулкынында
Тургай булып җаным атына.
Кайда, диеп мине сорамагыз —
Мин бәхетнең өске катында.

Бар йөрәгем кубарылып тибә,
Мәхәббәткә күңел талпына.
Әллә кайда диеп уйламагыз —
Мин сөюнең өске катында.

Әллә кайда түгел, монда гына,
Мин хыялның уйнак атында.
Әйдә бергә, сез дә соңламагыз —
Мин хыялның өске катында.

Ак болыттай ак уйларга чумып,
Басып торам дөнья чатында.
Кая китте, диеп сорамагыз —
Мин яшәүнең өске катында.

* * *

Мартлар булып керден тормышыма,
Умырзая булып яралдың.
Җиде бикле ялгыз күңелемә
Әфсен-серле ачкыч табалдың.

* * *

Салкын яңгыр.
Кайнар яшьләр.
Берни әйтмә,
Бер сүз дәшмә.

Җиңеләймәс
Минем хәлем.
Ярдәм итмәс
Бәхет шәлең.

Басып торам
Кыл өстендә.
Гамем сибәм
Дустым төнгә.

Төн генә тик
Мине аңлый.
Ул таш бәгырь
Була алмый.

Җиле белән
Юата ул,
Йолдызыннан
Нур ата ул.

Басып торам:
Төн һәм үзем.
Син теләдең
Шулай үзең...

Караңгы төн
Миңа әшнә.
Берни әйтмә,
Бер сүз дәшмә.

Кайнар яңгыр,
...Салкын яшьләр...

* * *

Тәрәзә төбендә песнәкләр
Чыркылдый көлешә-көлешә.
Күңелем сөюгә уралган —
Ә тышта кар ишә, кар ишә...

Кошларга җим сиптем. Аларга

Сөенү, шатлану килешә.
Уйларым язларда чуалган —
Ә тышта кар ишә, кар ишә...

Песнәкләр тәрәзгә чиертәләр,
«Ай рәхмәт!» диешә-диешә.
Йөрәгем ялкынга чорналган —
Ә тышта кар ишә, кар ишә...

...Песнәкләр юк инде. Тәрәздә
Шук кояш нурлары биешә...
Йөрәгем бушлыкта югалган —
Күңелдә кар ишә, кар ишә...

## * * *

Ноябрьләр ахырында
Үз яныңа чакырдың да
Урап алдың мине, Сөю,
Урлап калдың мине, Сөю,
Ноябрьләр ахырында.

Гамьле күзләр ахырында
Үз яныңа чакырдың да
Йөрәгемә кердең, Сөю,
Ак бәхеткә төрдең, Сөю,
Гамьле күзләр ахырында.

Ноябрьләр ахырында
Үз яныңа чакырдың да...
Күңелгә моң килде, Сөю...
Синдә калам инде, Сөю...
Гамьле күзләр ахырында.

# Еллар үтәр...

Еллар үтәр. Бәлкем, шунда гына
Барын аңларсың син — соң булыр,
Күзләремдә сүнгән моң булыр.

Еллар үтәр. Шашып давыллаган
Күңел дөньям инде тын булыр,
Тынуым да инде чын булыр.

Еллар үтәр. Хыялымда һаман
Синең күләгәле сын булыр,
Күккә карарсың син — соң булыр.

## * * *

*Айсылуга*

— Синең исемеңнең баш хәрефе
Эйфель башнясына охшаган...
— Ышанам...

— Синең исемеңнең баш хәрефен
Әйтеп Америка ачканнар...

— Ачкан бар...

— Андромеда синең өчен яна,
Күктәге Ай балкый тик сиңа.
Зур дәрьяның дәрьялары булган
Горур, шаулы Атлантик сиңа...
— Ник миңа?..

— Алмагачлар: «Син!» —
дип чәчәк ата,
Аккошлар да сине эзлиләр.
Ак күңелле батыр ак егетләр
«Аһ!» димичә бер дә түзмиләр...
— Күзлиләр?!

— Дөньядагы бөтен материклар
Синең исем белән башлана.
Кай тарафка уем юнәлсә дә,
Синең исем күзгә ташлана...
— Ташлама...

# * * *

Кыш уртасы. Тышта җиләс.
Бозланган карлар юеш.
Түбәләр елап утыра.
Уйлар чуалган — үлеш!

Каеннарым сөенешә:
«Яз, яз!» — диярдәй булып.
Чырык чыпчыклар да оча
Күккә тиярдәй булып.

Салкын кышлар уртасында
Язлар килә димени?..
Карлы болыт арасыннан
Кояш көлә димени?..

...Әй, җүләрдер бу табигать,
Салкын кышлары — юаш.
Түбәләр елап утыра —
Син дә аларга елаш!..

Бу сөенеч елавымы,
Әллә кайгы яшеме?
Кар очарлык төнге күктә
Уйның язлар яшене.

Җебегән кышны юата
Тилергән яз җилләре.
Котып уртасына шулай
Язлар булып кил әле!..

...Тиле кыш яз иркәсендә
Эрер дә бетәр инде.
Һәр ел саен өметләнеп
Мәхәббәт көтәр инде...

## И Ходам, Мәхәббәт бир!

*(Давид Самойловка ияреп)*

Бар өметләр сүнгәндә,
Җир тынлыкка күнгәндә,
Ачынып кычкыр, бәндә:
«И Ходам, Мәхәббәт бир!»

Күктән кояш киткәндә,
Ярсу елга кипкәндә,
Күңелдә моң типкәндә,
И Ходам, Мәхәббәт бир!

Ялгыз шәм талпынганда,
Җанда гамь атынганда,
Ачы яшь татыганда,
И Ходам, Мәхәббәт бир!

Бәхет ишек япканда,
Инде төптә ятканда,
Ниндидер җылы җанда —
И Ходам, Мәхәббәт бир!

## Ярый, мине кызганма да...

Көннәр буе көтеп ятам
Синең шалтыратуны.
Туктат инде, эндәшмичә,
Җанны аптыратуны.

Ярый, бер төн йокламадым,
Бер төн өйдән чыкмадым.
Телефондагы сәгатьтән
Минутларны чутладым.

Кесә телефоным дәшми,
Бер тын-тавыш чыгармый.
Синең хәбәреңне көтеп
Ничек түзәдер армый?

Шалтыратуыңны көтеп
Йөрәкләрем сыза ич.
Ярый, мине кызганма да,
Телефоным — кызганыч.

Мине бер уйламасаң да,
Аны бер жәлләр идең...
...Кинәт телефон аркылы:
«Исәнме! Хәлләр?..» — дидең.

## * * *

Мин сине бер көн буена
Уйламам дигән идем.
Уйламаган кеше булып
Кыланам дигән идем.

Мин сине бер көн буена
Сагынмам дигән идем.
Йөрәгемне карга салдым —
Кабынмам дигән идем...

Юк. Булмады. Минем күңел
Моңга уралган кебек...
Бер көн түгел, бер сәгать тә
Синсез торалмам кебек.

## Без икебез бербөтен

Алдагы юл өзелсә дә,
Хыяллар булса төтен,
Сүндермик без, сүрелдермик
Җанда яшәү өметен.

Әгәр дә иртәгә калса
Гомерем бер чеметем,
Белеп тор: син — минем җаным,
Бәхетем һәм өметем.

Без икебез бербөтен бит,
Без икебез бербөтен.
Син — минем сыеныр кыям,
Ә мин — синең бөркетең.

## Бер җылы сүз...

Бер җылы сүз көтә күңел:
беркайчан да
ишетмәгән,
яраттырган,
үчекләгән.

Бер җылы сүз көтә күңел:
йөрәгемне
кубарырлык,
хисләремне
тугарырлык.

Бер җылы сүз көтә күңел:
күңелемне
бушатырга,
җанны җанга
куша торган.

Бер җылы сүз көтә күңел:
хыялларга
илтә торган,
бәхет сазын
чиертә торган.

Бер җылы сүз көтә күңел:
салкын бозны
эретерлек,
җан үзәген
чеметерлек.

Бер җылы сүз көтә күңел...

Әйтерсеңме?..

* * *

Син үзеңнән качасыңмы?..
Әллә миннән качасыңмы?..
Үз орбитаңда әйләнеп
Америка ачасыңмы?..

Синең хисләр бәйдә тора,
Ник иреккә чыгармыйсың?..
Бер җылы да тоялмаса,
Минем күңел чыдармы соң?..

Ике җанның арасына
Ник суык җил кертәсең син?..
Бер йотым наз да бирмичә
Миннән нәрсә көтәсең син?..

Күңелеңне тутырырга
Минем җылым җитәдер дә...
Минем күңел җавап көтә —
Тынлык. Ничек түзәргә?..

...Син үзеңнән качасыңмы?..
Әллә миннән качасыңмы?..
...Суык җил кайнар вулканнан
Боз өеме ясасынмы?

* * *

Үлем...
Сәер нәрсә.
Әгәр Алла
Газраилен
җибәрсә...
Юк-юк,
Бөек Аллам,
Газраилнең
җанын
үзем алам,
мин аны
мәхәббәткә
салам...
Тоз суда
эрегән кебек
эресен ул,
мең үлсен дә
терелсен ул,
наз-сөюдән
яралсын ул,
бар күкләргә
таралсын ул...
Гашыйкларның
бу дөньяда
вәгъдәләре,
антлары бар —
бәхетле булып
яшәргә
Хаклары бар!..

Хаклары бар!..

*** * ***

Өф-өф итеп өрәсең син
Мәхәббәтем учагына.
Ул тагын көчлерәк яна,
Сине дәшеп кочагына.

Кулың белән йөзең каплап,
Омтыласың салкынлыкка.
Оялуың тарта сине
Бушап калган тын тынлыкка.

Ялкынга да кызыгасың,
Аңа чумарга телисең.
Йөрәгеңдә ут уйнатып,
Эх, бер дуларга телисең.

Тартышасың, утка керсәң,
Кире чыкмасыңны белеп.
Сизәсеңме, учагыма
Үзең барасың ла кереп.

## Җырым бар...

Бу гөлләрне сиңа бүләк итәм,
Искә төшсен җәйге болыннар...
Һәр кешенең нәни йөрәгендә
Олы мәхәббәткә урын бар...
Күңелемдә сиңа багышланган,
Сиңа гына дигән җырым бар...

*** * ***

Күңелемне
нурлаучым,
Йөрәгемне
урлаучым,
Саф хисләргә
ураучым,
Бәхет, сөю
юраучым...
Мин — корбаның,
син — аучым,
Син — дөнья,
мин — юлаучың...
Син — ЯЗМЫШЫМ —
юрау чын...

## Бу язларны сиңа бүләк итәм...

Бу язларны сиңа бүләк итәм,

Ул язларга сыйган барсы да —
Мәхәббәт тә, күңел сафлыгы да,
Җанны эретерлек ярсу да.

Бу язларны сиңа бүләк итәм,
Ул язларда яшәү моңы бар.
Күктән тамган тамчы чыңнарында
Сөенеч һәм бәхет тыны бар.

## * * *

Чык син, кояш,
яктырт күңелемне!..
Чыклар булып
җиргә түгелдемме?..
Яфрак булып
җилгә сибелдемме?..
Мин идем ул, кояш,
син белдеңме?..

Син каядыр
болыт шәүләсендә...
Йөрәгеңә
хисләр бәйләнсен дә,
Җан тирәли
җаным әйләнсен дә...
Чык инде, чык
янга, әйдә, син дә!..

Куркасыңмы,
әллә шүрлисеңме?..
Әллә мине
бер дә күрмисеңме?..
Җаным ярып
бирәм саф хисемне...
Бар ул сөю,
шуны белмисеңме?..

...Болытларны
үзем куам хәзер,
Синең өчен
мин барсына әзер...
Чык инде, чык,
яктырт күңелемне!..—
Тоям тиздән
сөеп үлеремне...

## * * *

Кояш кунган күзләреңә
Тутырып бер карыйм әле.
Яшәү моңы дәрьясыннан
Җаныма тын алыйм әле.

Синең күзләр Кама кебек —
Иксез-чиксез, тирән-тирән.

Алсу таңнар яктысында
Бәхетемә якын киләм...

Гәрәбәдәй күзләреңдә
Ак болытлар агып бара...
Шул болытлар икебезне
Киләчәккә алып бара...

...Мөлдерәмә ике караш —
Җанның җанга кагылышы...
Күзләреңдә минем күзләр,
Карашымда...
Синең күзләр чагылышы.

## Мин сине сагынганмын!..

Күрдеңме соң баш өстеңнән
Ак болыт агылганын,
Шул болытлар арасыннан
Елмаю табылганын?..

Күрдеңме соң серле төннең
Зәңгәр моң ябынганын,
Тылсымлы ай нурларының
Шул моңга кагылганын?..

Күрдеңме соң уйсулыкта
Көмеш күл чагылганын,
Бер аккошның ярсый-ярсый
Канатын кагынганын?..

...Дөньяны кочардай булып
Мин сине сагынганмын!..

## * * *

Ишекләр ачыла,
ишекләр ябыла,
чәчләргә ак карлар кагыла...
Гомерне үткәндә,
елларны сүткәндә
үзеңә тиң парлар табыла...

## Су ташый кыз...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Көянтә, чиләкләре...
Көянтәсен кочып алган
Ак шома беләкләре...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Сусавын басмакчымы?..
Юлына сөйгәне чыкса,
Йөрәген ачмакчымы?..

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Тамчыдай адымнары...

Мөлдерәмә күзләрендә
Саф чишмә чалымнары...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Офыкка карый-карый...
Толымлап үргән чәчләрен
Яз җиле генә тарый...

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Эх, чишмә булсаң икән!..
Пар чиләкнең ирнәвеннән
Су белән тулсаң икән!..

Су ташый кыз Ак чишмәдән,
Иренендә чык суы...
Юлына сөйгәне чыкса,
Кузгалыр җан ярсуы...

## Иртә яздан мине эзлә син...

Килеп кердек сары көзгә дә...
Гамьле каен җиргә тезләнә...
Төссезлектә җаным югала,
Буш тарафтан мине юллама.

Бураннардан мине эзләмә,
Юлыкмассың минем эзгә дә...
Кулга алсаң, кар да югала...
Ак карлардан мине юллама...

Тереклекне саклар өчен лә,
Бөре тибә кайры эчендә.
Умырзаяларны өзмә син,
Иртә яздан мине эзлә син...

## * * *

Чык суында юдым битемне.
Иркәм, миннән хәбәр көттеңме?..
Кайтып киләм җәйге иртәдә,
Таң нурлары булып иркәлә...

Ал гөлләрем — бүләк итәргә,
Вәгъдә биргән идең көтәргә.
Уйчан саба җиле юлдашым,
Синең янда гына юл башым.

Тәнем йөзә татлы таң буйлап,
Йөгерешә дулкын җан буйлап...
Ямьле гөлләр минем кочакта,
Каршыма чык, кысып кочакла!..

## Зәңгәр сирин

Зәңгәр сирин, дымлы һава.
Тышта җылы яңгыр ява.
Ә син сирин ышыгында —
Шундый рәхәт, ышык монда...

Җил-яңгыр да сиңа тимәс,

Күңелкәең иләс-миләс...
Янып-көеп йөргән чагың,
Чәчәк аткан сөю багың...

Зәңгәр сирин арасында
Рәхәтләнеп каласың да,
Чәчләреңә сирин кадап,
Елмаясың күккә карап...

Кулларыңда зәңгәр чәчәк.
Йөрәгеңдә яшәячәк
Мәхәббәтнең иң зурысы,
Сөенечнең иң олысы.

Иренеңдә бәхет дымы,
Янәшәңдә сирин сыны.
Офыкларны нурга манчып,
Шаян кояш тора качып...

## * * *

Син киләсең бүген,
Көтеп үтә төнем.
Вакыт тынын эчеп
Саркый татлы өнем.

## Синең күзләр

Якты коңгырт күзләр,
Мин табынган күзләр.
Күктә йолдыз булып
Төн кабынган күзләр.

Бәхет сөенече
Гел агылган күзләр.
Өмет чаткылары —
Нур кагылган күзләр.

Күзләреңне күреп,
Мең абынган сүзләр...
Җаным аша карый
Мин сагынган күзләр.

Якты коңгырт күзләр,
Моң чагылган күзләр...

## Элегия

Телефонда тынлык.
Ә күңелдә
Диңгез шаулый, дулкын чабыша...
Сөйгән ярлар бер кавыша алар,
Сөйгән ярлар бермәл табыша...

## Сагыну җыры

Утлы сөю хисләремне
Көмеш җептәй сапладым.
Ак болытка хатлар яздым,
Акты-китте хатларым.

Кояш нурларына төреп,
Сиңа сәлам җибәрдем.
Ул офыкка батты-китте,
Йөзгә төнге җил бәрде.

Ай яктысын карам итеп,
Сиңа шигырь юлладым.
Аем гына качты-китте,
Таң атарга — бер адым.

...Җил артыннан хатлар яздым,
Очты-китте хатларым...
Иң-иң кайнар хисләремне
Күрешүгә сакладым...

## * * *

Синең канны эчкән черки
Минекен дә эчкәндер, бәлки?..

## * * *

Чыклы тәрәзләрдән дым бәрә,
Үләннәрдә юеш күләгә.
Таң атмаган, кояш чыкмаган,
Җиләс җиргә нурын сыкмаган.

Төн салкынын җандай тоя да
Кочаклашып йоклый ояда
Табигатьнең гүзәл кошлары.
...Чемер-чемер... әллә кыш тагы?..

Тәнем буйлап йөгерә суыклык,
Сиздерәме әллә син юклык.
Минем җанга җылы керәлми,
Нигә шунда мендәр терәлми

Тамчы-тамчы тирле аркага...
Йөрәк кенә тыштан кар кага.
Чәч бөртеген урап боз төргән,
Синсезлекме башка төкергән?..

Күзләремә йокы иңәлми,
Өметсезлек мине җиңәлми.
Сине көтәм, таңның атканын,
Җанга кояш керер, аппагым...

## * * *

Салкын төнне ярып кайтып киләм,
Бәгыремдә сөю-учагым.
Ялкынымны төнгә күчерергә,
Тын халәткә гыйшык эчерергә
Кирәк синең кайнар кочагың...

## * * *

Мин җансыз яшәдем бугай
Тулы бер мәңгелек буе.
Күз төпләрем салкын иде,
Күңелемдә — кипкән кое...

Җан өрдең син һәм тудырдың
Мине сөю өереннән.
Күңелемдә коем шашкын
Хисләр белән өерелгән.

Ташып чыккан, мөлдерәмә...
Күзләремдә яшәү моңы,
Сулышымда кайнар вулкан —
Бәхет тыны, сөю тыны...

Җанымның кап уртасында
Гөлләр үскән кочак-кочак.
Ут-чәчәкләр арасында
Мәңге сүнмәс эссе учак.

## * * *

Җиденче төш күрәсеңдер
Җиде төн уртасында...
Мин генә кырык әйләнәм
Ялгызлык юртасында...

## Сине уйлап...

*(Тулай торак бүлмәсендәге уйлану)*

Казан каласында
Ялгыз гына ятам.
Офыкларга карап,
Тирән уйга батам.

Көннәр никтер салкын,
Көннәр никтер елак...
Мин Казанга якын,
Җаным аннан ерак.

Томырылып карыйм
Лаеш тарафына.
Әйдә, язмыш, мине
Йөз кат, мең кат сына!..

Тәрәз каршымдагы
Каеннарны шаулат.
Минем уем йөри
Әллә кайда шаулап.

Ничәнче көн инде
Кояш качкан күктән.
Хәят күңеленнән
Моң-сагышлар үпкән...

Карашларым эри
Офык читләрендә.
Мәхәббәтем ерак —
Лаеш чикләрендә.

Ул якын да кебек —
Күңелемдә җылы.
Йөрәгемдә аның
Йөрәгенең җыры...

Мин аның янында,
Ул да янәшәмдә.
Ак офыкка карап:
«Сөям!..» —
дип дәшәм дә...

Мөлдерәмә күңел
Бер чайпалып китә.
Гамьнәр өермәсе
Аны алып китә.

Лаеш тарафында
Гашыйк җаным эри.
Айлы төнне ярып,
Ярсу җаным йөри.

Казан каласында
Ялгыз гына ятам.
Сагышларны ертып,
Ал таң булып атам...

## Әйдә мин көтүче булам...

Әйдә мин көтүче булам,
Китәбез тауга карап.
Елмаеп көн каршыларсың,
Җилдә чәчеңне тарап.

Иртә таңнан мин көтүдә,
Син учакта калырсың.
Тирмәбезнең тирәләрен
Үз кулыңа алырсың.

Кич җиткәндә мин кайтырмын
Хуш исле учагыңа.
Ә син килеп сарылырсың
Кайнар киң кочагыма.

Мин сине сөеп туялмам,
Назлармын, иркәләрмен...
Эх, синең көдрә чәчләрең,
Чәчтәге тәңкәләрең...

...Күпме янсаң, тартышсаң да,
Булмый тормышка ярап...
Әйдә мин көтүче булам,
Китәбез тауга карап...

ТУЛАЙ ТОРАК БҮЛМӘСЕНДӘГЕ
УЙЛАНУЛАР...

*(Цикл)*

## Аяк тавышың

Коридордан үтеп киттең
Тиз-тиз атлап,
Мин генә тик җәфаланам
Шигырь ятлап.

Бер китапка, бер ишеккә
Карап торам.
Көтмәгәндә адымнарың
Тына... тына...

Аяк тавышларың булып
Йөрәк тибә.
Шул ритмда гүя кояш
Нурын сибә...

...Миллионнар арасыннан
Мин танырмын.
Шул тибешнең уртасында
Югалырмын...

Синең башмак кыштырдавы
Бер көй сыман.
Күңелемә өмет нуры
Бөрки сыман...

Колагымда кыштыр-кыштыр
Синең адым.
Шигырем дә онытылды
Менә тагын...

Бер югала, бер көчәя
Башмак шавы.
Ишек ачык, килеп кенә
Кер син бары...

## * * *

Песнәк килгән тәрәз каршыма:
«Сөйгәнеңнән хәбәр бар»,— диме?
«Яннарына оч син, бар»,— диме? —
Бүлмә хәзер миңа тар сыман.

Нәни песнәк шакый тәрәзгә:
«Ни көтәсең, ике уйлама,
Ул да көтә, ул да уйлана», —
Түземлегем җитәр бик әзгә.

...Песнәк булып очтым янына.
Алда сине күрер мизгелләр,
Уңга-сулга сибәм тик гөлләр,
Яз китереп көзләр таңына.

## Дүртенче кат... Бишенче кат...

Дүртенче кат... Бишенче кат...
Ике этаж арасы...
Өстә яши, күрсә дәшми
Минем йөрәк ярасы.

Дүртенче кат... Бишенче кат...
Идәннәре как такта.
Көн туктамыйм, төн йокламыйм —
Бар уем синең хакта.

Дүртенче кат... Бишенче кат...
Мәхәббәт сукмаклары.
Ничә тапкыр безнең җаннар
Бу сукмакны таптады.

Үзем дүрттә, ярым биштә —
Йөрәгем аның белән.
Сер бирмисең, ник килмисең —
Сөям бар җаным белән.

Дүртенче кат... Бишенче кат...
Кереп чыгарга була.
Тилмертәсең, үзем менәм,
Күпме чыдарга була?..

Дүртенче кат... Бишенче кат...
Ике йөрәк арасы.
Без барыбер гомерлеккә
Икәү бергә каласы.

## Китәсең дә югаласың...

Китәсең дә югаласың
Имтихан арасында.
Берүзем утырып калам
Таш Казан каласында.

Уку гына синең уйда,
Минекендә — син генә.
Бүлмә тәрәзәмә чиертә
Кышкы суык җил генә.

Кар сибәли ара-тирә
Син киткән сукмакларга.
Артыңнан җилдерер идем
Ярсу, уйнак атларда...

Уем атлардан да җитез —
Синнән алда чаба ул.
Сезнең авыл юлларына

Җан нурымны яба ул.

Синең өең монда гына,
Минеке — әллә кая.
Бер көнгә килеп китәсең,
Туң юлдан тая-тая.

Әллә каян, әллә нидән
Бер сәбәп табасың да,
Китәсең дә югаласың
Имтихан арасында.

Буранга кереп чумасың,
Күкләргә ашасыңмы?..
Сәбәп-сәбәп дигән булып,
Әллә алдашасыңмы?..

Мин — беркатлы, мин ышанам...
Тиздән янга килерсең,
Сагыну сагышларымда
Ак кар булып эрерсең.

## * * *

Бишенче кат — җиде кат күк,
Дүртенче кат — җир өсте.
Мин гади җир егетемен,
Ә син фәрештә төсле.

Бишенче кат — минем сөю,
Дүртенче кат — терәгем.
Синең күңелең янында
Минем очкын-йөрәгем.

Бишенче кат — синең сарай,
Дүртенче кат — минем өй.
Ике катның уртасында
Без чыгарган моңлы көй.

Бишенче кат — минем хыял,
Дүртенче кат — чынбарлык.
Ике ялкын, ике дулкын,
Зур дәрьяны чыгарлык.

Дүртенчк кат
Шатлыгын, кайгысын
Күңелем кичерә...
Ышаныч көч бирә...

## Айның яктысында

Болыт арасыннан,
Төннең карасыннан
Уйчан гына гүзәл ай чыга.

Дөнья хозурында,
Айның пакь нурында
Күңел белән йөзәр җай чыга.

Айның яктысында,
Еллар чаткысында
Утырам мин күккә күз салып.

Аем балкый көлеп,
Салкын җылы өреп,
Кара төнгә кайнар эз салып.

Башта айга карыйм,
Аннан йолдыз саныйм,
Үзем белән үзем сөйләшеп.

Ә ай уйчан гына,
Бик оялчан гына
Күктә йөри нурын өләшеп.

## * * *

Хыял иле, хыял диңгезе —
Киләчәкнең төпле нигезе.

## Көз җыры

*(Фридрих Хеббелга ияреп)*

Мин көзләргә карый алмыйм,
Һава — дым, сулау кыен.
Болытлар әйтәләр кебек:
«Салкын яңгырда коен!..»
Пычрак басу юлларында
Көз көйли соңгы туен.
Шәрә агачлар серләшә —
Әйтерсең соңгы җыен.

Күптән җыеп алдык инде
Мул табигатьнең сыен.
Үткәннәргә карый-карый
Авырта инде муен.
Ямьле җәйнең көннәреннән
Китәлми әле уем.
Тагын көзләргә керәбез —
Карап торуы кыен...

## Бәхет кайдадыр?..

Белмим, бәхет
кайдадыр,
Бәлкем, якты
айдадыр?..
Әллә ул
галәмдәме?
Шагыйрьгә —
каләмдәме?..
Бәхет ак
болыттамы?
Туып-үскән

йорттамы?..
Әниең булудамы?..
Сеңелең туудамы?..
Мәктәпкә йөрүдәме?
Туйганчы көлүдәме?..
Алсу таң
атудамы?
Тормыш
яратудамы?.. —
Белмим, бәхет
кайдадыр,
Бәлкем, якты
айдадыр?..
Үз бәхете һәркемнең...
Йолдызы күп ич төннең.
Алар да төрле-төрле,
Нәкъ кешеләр шикелле.

## * * *

Тапталган сукмаклар буйлап
Алга карап барам.
Урманнар, яланнар аша
Үземә юл ярам.

Кечкенә елга аркылы
Яңа күпер төзим.
Биек тауларга үрмәлим,
Дәрьяларда йөзим.

Болытларга җитмәсәм дә,
Җырым — җирдә томан.
Ә иҗатым — урмандагы
Бер яшь кенә болан.

## Шигырь

Күңелне кытыкла,
Шигырь!
Искермә, тутыкма,
Шигырь!
Йөрәктә шытып тор,
Шигырь!
Һәр җанны тотып тор,
Шигырь!..

## Агыйделдә боз китә

Һава рәхәт, җил салкынча,
Апрель кояшы күктә.
Көчен җыеп бер талпынса,
Агыйделдә боз китә.

Елга исе һәм боз исе
Тәнне йомшартып үтә.
Язгы җилле айлы кичне
Агыйделдә боз китә.

Күңелдә яз, йөрәктә яз,
Яшьлек йомгагын сүтә.
Сөрән сала үрдәк һәм каз:
«Агыйделдә боз китә!»

Тал песиләре уйнаклый,
Җил аларны биетә.
Тоз сипкәндәй элпә шартлый,
Агыйделдә боз китә.

Шушы гүзәл язгы кичне
Күңел нәрсәдер көтә.
Тибрәтеп иң нечкә хисне
Агыйделдә боз китә.

* * *

Еллар уза, еллар ага,
Барысы кабатлана...
Бер җылы сүз
ишетсәң дә,
Күңелең канатлана.

* * *

Чәчләрем дә әз-мәз
агаралар,
Ә офыкта күпме
баганалар...
Баганалар саен
бер ел бара.
Гомер үтә, алар
артта кала.
Чыбыклары — көннәр,
төрле-төрле...
Безне тарта күкме,
әллә җирме?..

...Офык читләре дә
агаралар.
Әле алда күпме
баганалар...

* * *

*(«Агыйдел» җыр һәм бию ансамбленә)*

Нинди аһәң, нинди көй бу
Таң җилләре китергән?
Чәчәкләр дә шушы көйгә
Елмаешып исергән.

Нинди аһәң, нинди көй бу,

Килә ул кай тарафтан?
Дөнья сүзсез моңны тыңлый —
Кем соң аны яраткан?

Нинди аһәң, нинди көй бу,
Уй-хыялга чумдыра?
Бер мизгелдә табигатьне
Уйландыра, тындыра.

Нинди аһәң, нинди көй бу
Агыйдел буйлап чаба?
Кояш нуры булып оча
Ерак офыкка таба.

Нинди аһәң, нинди көй бу
Галәмне яңгырата?
Ак болытлар якты җиргә
Илаһи яңгыр ата.

Нинди аһәң, нинди көй бу? —
Ул миңа якын, таныш.
Туган ягым авазы ул,
Тарта җанны Актаныш.

## Студент еллары

Эх, студент еллары ла,
Онтылырлык булмады.
Искә төшсә, тибрәнәләр
Күңелемнең кыллары.

Эх, студент еллары ла,
Иң күңелле чаклар ул.
Гүзәл хискә — мәхәббәткә
Сөю тулы хатлар ул.

Эх, студент еллары ла,
Югалмас хатирәләр.
Алар киләчәккә өмет,
Зур ышаныч бирәләр.

Эх, студент еллары ла,
Онтылырлык булмады.
Якты булсын, аклы булсын
Киләчәкнең юллары.

Мәңге сүнмәс учак булып,
Изге калын китап булып
Сакланыр ул, сакланыр,
Йөрәк түрендә калыр!

## Җырла әле

Җырла әле,
күңелләрем күтәрелсен,
моң бәрелсен
йөрәкләргә.
Дәртле көйләр
юсын әле дөнья йөзен,
ике күзен
сөртсен әле,

тузаннарын...
Искә алмый гомерләрнең
узганнарын,
җырла әле,
йөрәкләрне җилкендереп,
селкендереп
зәңгәр күкне.
Дәртле моңың
тишеп чыксын озоннарны
һәм аннары
галактикаларга очсын да ул,
әсир итсен
анда торганнарны.
Планеталар
рәхәтләнеп биесеннәр,
сөенсеннәр бар җаннар да.
Дәртле көйләр
өметләрне үстерсеннәр,
ә сүнгәннәр
терелсеннәр.
Төренсеннәр
бар йөрәкләр алга-гөлгә —
бергә-бергә
җырлыйк әле,
бар күңелләр күтәрелсен,
моң бәрелсен
йөрәкләргә.
Эретсен дә ул бозларны,
җылытсын йолдызларны.

## Моң илчесе булу кирәк

Ак күңелне, саф күңелне
Чәчәкләргә күмәр өчен,
Үз көенә агып яткан
Чишмәкәйне үбәр өчен;
Төнге күктән йолдыз алып
Бар дөньяга сибәр өчен,
Буш тынлыкны җанландырып
Йөрәк сыман тибәр өчен;
Ай нурыннан аркан ишеп
Җиде күккә менәр өчен,
Яңгырдан соң тамчы булып
Җылы җиргә сеңәр өчен;
Яшел үлән исләреннән
Ләззәтләнеп көләр өчен,
Яшәгәнгә үкенмичә,
Нурга чумып үләр өчен...—
Моң илчесе булу кирәк.

## Октябрем

Октябрьдә тудым.
Ахры, үзем
Мәңгелеккә шунда калырмын,
Күптән көткән бәхет буразнасын
Нурлы көндә талмый ярырмын.

Октябрь ул — көз дип ашыкма син,
Җәйләргә тиң әби чуагы.
Октябрьгә барып үрелә бит
Гомеремнең сизгер йомгагы.

Октябрь — моң, тоташ алтын гына,
Канатларын кага каз-үрдәк.
Октябрьдә аваз салганмын мин,
Октябрьдә калыр рух, йөрәк.

Буш басулар җитди кыяфәттә,
Урманнарда серле шом ята.
Октябрьдә минем гомер юлым,
Язмышымны Ходай сыната.

Октябрьнең төне салкын гына,
Айлы күктә мәрҗән муенса.
Кемдер анда язгы серлелектә
Рәхәтләнеп моңга коенса,

Октябрем миңа илһам бирә,
Октябрем — минем кояшым.
Гүзәл көздә калыр көйрәк җаным,
Октябрем — бакый юлдашым.

## * * *

Ургып-ургып хисләр ага —
күңел тулы.
Ерак офыкларга таба
гомер юлы.

Урман-диңгезләр кичәсе —
алда бар да,
Язгы җил булып исәсе
бозлы ярда.

Тургай-кош булып сайрыйсы
зифа талда,
Үз юлың үзең сайлыйсы —
сәфәр алда.

Балык кебек суга чумып
йөзәселәр,
Давылларга киртә булып
түзәселәр...

Дөнья ямен, тәмен табып
көләселәр,
Ай нурын күңелгә ягып
үләселәр...

Ургып-ургып еллар ага —
касә тулы.
Чиксез офыкларга таба
гомер юлы.

## Кышкы иртә

*(Пушкиннан)*

Суык. Кояш. Көн ямьле.
Син йоклыйсыңмы әле?..
Тор инде, тор, чибәркәй,
Күзләреңне ач, син, әй!
Себер таң балкышына
Йолдыз бул син кышына...

Кич бит буран улады,
Тонык күк тә елады.
Болыт артындагы ай
Багып торды алтындай;
Ә син боегып йөрдең,
Тәрәзгә күз сал, сеңлем!..

Зәңгәр күкләр астында
Җәймә кар ята монда,
Ялтырый ул кояшта.
Карурман теге башта.
Бәс төргән яшел чыршы,
Бозланган инеш-җырчы.

Гәрәбә төс бүлмәдә.
Дәртләнеп яна әнә
Мичтәге имән утын.
Уйларым биеми. Тын...
Әллә коба бияне
Җигәргәме диямен...

Иртәнге кардан шуып,
Чаптырыйк аны куып.
Пырдымсыз ат йөгерсен,
Бушаган кырга керсен.
Барыйк урман янына,
Сөйгән елгам ярына.

## Халәт

Интегергә килгәнмендер җиргә,
Җәфа чигәр өчен туганмындыр.
Урмандагы сары сагыш төргән
Каеннарга, бәлкем, туганмындыр...

Кайрыларым минем киртек-киртек,
Яралардан саркый сөю каны.
Ап-ак карлар яраларны сөртер,
Суык назлар иркәләрләр җанны.

Тамырымда кайгы үзе ята,
Еламсырлык кунган иңнәремә.
Башны куям, йөрәгемне ачам
Көзнең шаян моңсу җилләренә.

Күңелемдә минем әллә нәрсә,
Сары яфрак белән тулган сыман.
Урмандагы тирән уйга чумган
Гамьле каен миңа туган сыман.

## Яңгырда

Су җепләре сузылганнар күктән җиргә —
Менәсе менсен, төшәсе төшсен дип...

* * *

Мин сөйләшмим таш диварлар белән,
Мин сөйләшәм энҗе карлар белән,
Мин серләшәм ләйсән яңгыр белән,
Арыш үскән шаулы яшь кыр белән.

Мин көлешәм серле йолдыз белән,
Ай янында Зөһрә-ялгыз белән,
Мин елмаям уйчан күккә карап,
Ак болыттай ак өметкә карап.

Мин тирбәләм тургай моңнарында,
Карурманның сәер шомнарында,
Мин эндәшәм челтер чишмәләргә...
Яз җиледәй көн дә искәләргә!..

Мин биешәм уйнак дулкын белән,
Һәрберсенең фигыль-холкын беләм...
Мин серләшәм тамчы-таллар белән,
Мин сөйләшмим таш диварлар белән.

* * *

Мин туганмын,
кемдер күчкән
бакыйга...
Кеше үлү —
олы кайгы,
ә тууы —
вакыйга.

* * *

Җан — күбәләк,
Күбәләк — җан,
Кунак булып
йөри чәчәктә...

* * *

Шигырь белән
яшим,
Шигырь белән
янам.
Шигырь булып

дәшим...
Шигырь — минем
ярам.

## * * *

Башым тулы миллион идеяләр,
Миллион шигырь әле тумаган.
Әйтерсең лә минем уй галәме
Ачылмаган төпсез чемодан!..

## Сусау

Шундый да сусадым бүген,
Миңа шигырь бирегез.
Күңелемдәге эссегә
Су сибегез берегез!

Шундый авыр, рәхәт түгел,
Күңел кибә башласа.
Кемдер моңа чыдый алмый,
Төнге күккә бау аса.

Берәү суга кереп чума,
Инде кире кайтмаска.
Күңел сулса, корып торса,
Адәм тәгәри аска...

Ә миңа шигырь бирегез —
Яңгыр яусын күңелдә...
...Шигырь, татлы тамчы булып
Күңелемдә җемелдә!..

## Яңа ел җыры

Бит кызарткан уйнак җилдән
Яңа ел исе килә.
Җилләр белән, җилләр белән
Бергә биисе килә!

Яуган кар бөртекләренә
Яңа ел төсе керә.
Бәйрәм безгә, бәйрәм безгә
Ак бәхетләр китерә!

Нидер көткән, өмет иткән
Йөрәк шашынып тибә.
Якты җиргә, якты җиргә
Күкләр мәхәббәт сибә!

## Галәм

Серле галәм,
Керле галәм,

Чиксез галәм,
Биксез галәм,
Тонык галәм,
Сынык галәм...

Серләреңне
Эзләп үткән
Гомер әрәм...

## Мизгел

Тургайлар сайраган болында
Беразга атымны тугардым.
Тын алам бормалы юлымда —
Уф, ардым.

Битараф тормыштан ялыккан
Җанымны ireккә чыгардым.
Күңелем түрендә калыккан
Гүзәллек эчендә югалдым.

Кечкенә инештән су алып
Чылаттым керфегем очларын.
Йөрдем мин бик озак югалып,
Иркәләп наз җилен учладым.

Арыган, сагышка тарыган
Күңелем җилләде, бушанды.
Юллардан бик озак барылган —
Үзем дә ышанмас-ышандым.

Матурлык, дөньяның тәмнәре
Якында, күзебез читендә.
Ни хикмәт, гомернең шәмнәре
Сүнәләр. Авыр да, читен дә.

Ашыгып, җилдереп атларда,
Куабыз дөньяны, куабыз.
Юл бирми дусларга, ятларга
яшибез.
Бәхетсез шуңа без.

Бер көнлек бәхеттән ни файда,
Иртәгә ул синнән ычкынса.
Бернисез бәхетле болай да,
Күңелгә моңлы бер кош кунса.

...Чәчәкләр сибелгән болында
Беразга атымны тугардым.
Ай, җитәр! Булыйм мин юлымда...—
Ак офык артында югалдым.

## * * *

Мизгелгә күземне йомдым,
Мизгелгә ачып калдым.
Салкын дөнья уртасында

Ялгызым басып калдым.

Беркем дә юк, бернәрсә дә —
Ялангач бушлык кына.
Әллә бу мираж гынамы?..
Ялганчы тышлык кына?..

Кояш та юк. Эңгер-меңгер.
Буп-буш тонык күк йөзе.
Ком өеме уртасында
Минем җаным берүзе.

Мизгелгә йомган күземне
Инде шар ачып торам,
Ком астыннан бер гөл шыткан —
Шаккатып басып торам.

## * * *

Кайгы төргән гамьле кичләремдә
Керәсең дә, әнкәй, төшләремә:
«Сабыр бул син, нык бул, балам,—
дисең,—
Мин гел синең янда калам,— дисең...»
Кайгы төргән гамьле кичләремдә.

Бәхет-шатлык тулы кичләремдә
Керәсең дә, әнкәй, төшләремә:
«Гел көлеп тор, газиз балам,— дисең,—
Синең өчен мин шатланам,— дисең...»
Бәхет-шатлык тулы кичләремдә.

## Этюд

Зәңгәр томан арасыннан
Алсу кояш елмая.
Җиһанның кап уртасында
Мәйдан тотты ул бая.

Чиксез офык магнит кебек
Тарта да тарта аны.
Якты күкне каплый бара
Караңгылык юрганы.

Җил дә исми, сайрар кошлар
Йоклыйлар. Дөнья тына.
Тик моңлы ай алсу нурлы
Таганында атына.

## Вакыт

Вакыт — сынау.
Чыдап була,
Түземлегең
Булса унау.

## Көз инде...

Үтте яз,
Үтте җәй —
Көз инде.
Елама,
Сорама —
Түз инде...

Бик моңсу,
Ямансу —
Көз инде.
Көннәрдә
Яшь тулы
Күз инде.

Әй, җилкәй,
Яфрагым
Өз инде.
Күктә шәм,
Җанда гамь —
Көз инде.

## Шундый кеше мин...

Шундый кеше мин:
йә елыйм,
йә көләм,
йә туам,
йә үләм.

Шундый кеше мин:
йә дөрлим,
йә тынам,
йә сынам,
талпынам.

Шундый кеше мин:
йә байыйм,
таң атам,
күралмыйм,
яратам.

Шундый кеше мин:
җиңеләм,
йә җиңәм,
йә ташыйм,
йә кибәм.

Шундый кеше мин:
йә туңам,
эрим дә...
үзем дә
белмим лә...

## * * *

Егермене уздым —
Килә ирлек.
Ирлек белән бергә

Чын шагыйрьлек.

* * *

Әй, көзкәем,
Көяз көзем минем!
Җаным-тәнем сиңа тартыла.
Шашкын күңел
Язга талпынса да,
Нигәдер гел көз яратыла.

Уйчан көзем,
Боек көзем минем!
Елак та син, кайчак көләч тә.
Күзләремдә
Өмет уйный башлый,
Көз кояшы күктән көлгәч тә.

Әй, көзкәем,
Алтын көзем минем! —
Елмаюың йокты үземә.
Тар сукмактан
Йөгерәм...
Очам гына
Баса-баса яфрак-эзеңә.

* * *

Яңгыр миңа охшаган,
Мин дә шулай бушанам.
Елыйм, һич туктый алмыйм —
Яшьләремне тыялмыйм.

Җил дә миңа охшаган,
Мин беркатлы, ышанам —
Тынгысыз исәм шулай,
Мин юньле исәр бугай.

Яз да миңа охшаган,
Ярсыган ул, сусаган...
Дөньяда сагыш моңы,
Күңелдә тамчы чыңы.

* * *

Агачтан
төштем мин
мәтәлеп —
җирнең тарту көче җиңде...

...Мин ятам
ятакта

әйләнеп —
бүген яту көче җиңде...

## Соңгы яфрак

*(Көзге җыр)*

Сары көзнең моңсу-уйчан җиле
Яфракларда сары фал ачкан.
Ак каеным бүген боек кына —
Соңгы яфрак елый агачта.

Өзелде дә төште соңгы яфрак,
Ак каенда сагыш сизелде.
Бар хыялым чәлпәрәмә килде,
Өметләрем сүнде, өзелде.

Җилфер-җилфер килә соңгы яфрак
Сагышларга чумган иртәдә.
Ак каеным бүген боек кына —
Күңлем елый, күңлем үртәлә.

Соңгы яфрак җилләр белән китте,
Өметләнеп күзләр таңына.
Ак каеным бүген бер сүз дәшми —
Күзләр инде минем җаныма.

Өзелде дә төште соңгы яфрак,
Ак каенда сагыш сизелде.
Бар хыялым чәлпәрәмә килде,
Өметләрем сүнде, өзелде.

## * * *

Кар өстендә
таплар —
Саргайган яф-
раклар.

Сарыланган
чакны
Дөньяга ак
капты.

Юл читләре
сары.
Юлда бәхет
кары...

Сары сагыш
берчак
Була икән
гел ак.

## Ялгызлык

Буш оя,
Буш дөнья,

Буш гомер.
Буш юллар,
Буш куллар,
Буш күңел.

## Иң якын дуска

Тормышка ышаныч беткәндә,
Бу дөнья тетмәмне теткәндә,
Җаным бер җылы сүз көткәндә,
Кер миңа үткәндә-сүткәндә.

Күңелем мең газап чиккәндә,
Тәрәзгә көз җиле чиерткәндә,
Чыгырым соң чиккә җиткәндә,
Кер миңа килгәндә-киткәндә.

Ышанып, яратып бер көлсәң,
Яз җиледәй булып бөркелсәң,
Ай булып янымда, һәй, йөрсәң...
Күңелем нурланыр, син керсәң.

## * * *

Ярым бушлык, ярым караңгылык,
Йөрәктәге тирән ярам кебек,
Шул ярамны учлап барам кебек,
Болай бару — соңгы чарам кебек...
Ярым бушлык, ярым караңгылык.

## Илдар абый

*Илдар Юзеев истәлегенә*

Күңелләрне телеп төшә,
Йөрәкләрне мең яралый
Синең юклык, салкын бушлык,
Илдар абый, Илдар абый...

Ап-ак кышның моңлы көне.
Бөтен җаным гамьгә тарый.
Синсез авыр. Карлар явар,
Илдар абый, Илдар абый...

Әнә дымлы тәрәзәдән
Моңсу итеп кояш карый.
Ул да сине сагынадыр,
Илдар абый, Илдар абый...

...Язлар җитәр, карлар китәр,
Тамчы тамар бертуктамый.
Күзем яшьле. Кемдер дәште:
«Илдар абый, Илдар абый...»

Яфрак булып шыбырдашкан
Гомерләрне еллар саный...
Кол Галидәй басып тора

Илдар абый, Илдар абый...

* * *

Сәгать саный...
Санасын ла...
...Беләм шәмнең
Соң мизгелдә
Мең талпынып
Янасын да...

* * *

Ялган шөһрәт,
Бер көнлек дан
Җитә бер төн чыгарга...
Һәр көн иблис
Куеныннан
«Тәмле кәнфит» чыгара...

* * *

Җирдән күккә
карап ятам,
күренә бар да.
Күкләр өчен
бу вакытта
кешеләр — Алла.

* * *

Мин — күкләр
малае,
йөримен бу җирдә
караеп.

* * *

Табигатем минем кыр казыдай...
Эх, очасы килә җирне ташлап!
Иксез-чиксез зәңгәр күк диңгезен
Йөзәсе лә килә бер колачлап.

Табигатем минем кыр казыдай...
Киң болыннар, иркен елгалары
Күңелемне тарта, ымсындыра...
Йөрәгемне камый еллар кары.

Табигатем минем кыр казыдай...

Кайнап торам, эх, очасым килә!..
Тормыш салган авыр арканнардан
Ычкынасым, бер бушасым килә!

Табигатем минем кыр казыдай...
Киң офыклар тарта күңелемне...
Җаным тоя: күккә очкач, җиргә
Киек каздай кире килеремне...

# * * *

*Соңгы сугышчы күмелгәч*
*кенә,*
*сугыш беткән санала...*

Гөл коя яфрагын...
Кәфен булып ята җиргә
яфраклар...
Син кайда ятасың?..
Үткәннәр хатасын
кем аклар?..

# * * *

Дөньяның өмет ишеген
Кирүк ачып керәсең дә...
Арттан килә тик бер аваз:
«Кирәкме мин берәрсенә?..
Кирәкме мин берәрсенә?..»

Тормышның ваклыкларыннан
Еларсың да, көләрсең дә...
Күңелемдә тик бер аваз:
«Мин кирәктер берәрсенә,
Мин кирәктер берәрсенә...»

Ялгыз калсаң, хыялыңны,
Өметеңне күмәрсең дә...
Җанны яра тик бер аваз:
«Мин кирәк бит берәрсенә,
Мин кирәк бит берәрсенә...»

# Каурый төште...

*Нур Баянга*

Мылтыгыңда утлы пуля ята,
Күңел ишегеңнән моң бәрә...
Атмый тору сиңа бер бәладер,
Язмый тору исә — мең бәла...

Айлы төндә окоп ышыгында
Ак кәгазьгә күчә моңнарың.
Чорлар аша үткән җырларыңны
Агыйделгә төшеп тыңладым.

Пар аккошлар йөзә тып-тын суда,
Актарыла йөрәк ызаны.

Сугыш барган кырлар янда кебек —
Җаным буйлап сагыш сызамы?..

Үткәннәрдән кайта йөрәк шавы,
Шарлавыклар булып ага моң...
Актарганда милләт сандыгыннан
Тарих тузаннарын кагамын.

Исән әле, исән синең җырың,
Йөрәкләргә бәрә җылысы...
Үзәгендә чәчәк балы исе,
Кош сайравы, нарат ылысы...

Тарих тузаннарын кояр өчен,
Эх, куясы утлы минаны!.. —
Аккош канатыннан каурый төште,
Кулларыма алдым мин аны.

## * * *

Шыбыр-шыбыр яуган яңгырда
Шыбырдаша яшел яфраклар...
Пәйгамбәрен гасыр көтә лә...
Аваз бирсә, күккә күтәрә...
Дога укый яшел яфраклар,
Җиргә кандай сауган яңгырда...

## Яңгыр

Күкнең моң тулы касәсе
коргаксыган җиргә түгелде.

## Җан

Тәпили... талпына биеккә...
Әйләнә бер тында киеккә...

## Гомер

Сулы идән буйлап тәгәрәгән витамин.

## * * *

Күк йөзен куертты бер болыт,
Кояшны каплады, яумады...
Калды тик күңелдә җөй булып,
Алдады, чукынган, алдады!..

## Тупыл мамыгы

Июнь башы. Тупыл мамык коя.
Бар җиһанга чәчә аклыгын.
Җәй эчендә ак кар явамени —
Нинди серле көн бу, аклы көн!..

Тәрәзәдән керә, ишекләрдән —
Анда-монда тупыл мамыгы.
Чәчләремә кунган ак мамыктан,
Әни, күңел сине таныды...

Синең дә чәч тупыл мамыгыдай,
Үзе йомшак, үзе ак кына.
Ак төс сиңа бик килешә, әни,
Көләч чагың, матур чак кына...

...Июнь башы. Тупыл мамык коя.
Әйтерсең лә дөнья ак болыт...
Һәр ел яуган мамык әниемнең
Чәчләренә кунган ак булып.

## * * *

Көн бүген сүрелгән,
Йоклаган, изрәгән...
...Сап-салкын су койды
Бер мәхлук бидрәдән...

## * * *

Җилле көн...
Җилли көн.
Кичәге кайгылар юк инде.
Тормышка ямь иңде, нур иңде...

## * * *

Төнге күккә таш аткан идем,
Йолдызлар коелды да бетте.
Бар тынлыкны караңгылык үпте...

## * * *

— Караңгы...
— Уйларыңда лампочка кабыз...

✻ ✻ ✻

«Пип-пип» килеп уйный
Бер кайгысыз бала...
...Үткәннәрен уйлый
Ялгыз калган ана...

✻ ✻ ✻

Эссе...
Эссе...
Кояш кызды...
Телләр телгә ябышты...
Кояшка кызыгу уйны
Ялгыштырды... ялгышты...

## Мәхәббәт

Урланган йөрәк урынында
туган дым тамчысы...

## Күңел

Кыллары тартылган думбра.

✻ ✻ ✻

Дөньяда яшеллек...
Без аны яшердек —
Күрмәсен очлы күз дошманнар...
Елмаеп яттылар,
Тоттылар, саттылар
Акчага кол булган куштаннар...

## Очам гына...

Яктырт, Кояш, бар дөньямны —
Мин яратам, сөям аны!
Күкрәк киереп сулыйм, исним,
Шашам бугай, әллә нишлим...

Мәхәббәттән ташкан җаным,
Күккә ишек ачкан җаным
Бөтерелә бөтерчектәй,
Һава иңли өтер-җептәй...

Очам гына өскә таба,

Күңелемә эссе каба...
Шатлык уттан утка сала,
Рәшә җаным күктә кала...

Чәбәләнәм арлы-бирле...
Дөнья — матур, дөнья — серле!..
...Татып бәхет дигән тәмне,
Эх, яшисе килә мәңге!..

## * * *

Эсселе-суыклы
яңгыр тамчылары.
Бүген тагын тышта
яңгыр тамчылады...
Тамчыламады ла,
талгын гына койды...
Болыт бөртекләре
күңелемә сыйды.

Бер эсселәп алдым...
җаннан суык үтте.
Эсселе-суыклык
бәгыремне өтте...
Өтмәде лә инде,
әкрен генә телде,
Сагыш үзәненә
боз тамчысы элде.

Гамьсез-ямьсез калдым,
бар моңнарым туңган.
Гүя бөтен күңел
суык белән тулган...
...Кышны кискән сулыш —
сөю көчлелеге,
Йөрәк тибешемнең
вулкан эсселеге.

## * * *

Чебеннәргә рәхәт.
Идән-түшәм —
Аерма юк, барыбер аларга...
Түшәмдәге чебеннәр дә кайчак
Төшештерә савыт яларга...

## * * *

Ник кысасың, авыртасың, йөрәк,
Нәрсә булды сиңа, әйт әле?..
Сөмсереңә ярамадымыни,
Соңлап, дулап килгән җәй тәме?..

Ник кысасың, куырыласың, йөрәк,
Сөю һәм наз сиңа җитмиме?..

Язмыш салган тутык богаулары
Чиксез гомереңне чиклиме?..

Ник сызасың, борчыласың, йөрәк,
Кояш булып мәллә янасың?..
Бу дөньяда йөрәксезләр күпме,
Алар әнә гомер санасын...

Ник дулыйсың, уйланасың,
йөрәк?..—
Күк күкләргә әле ашыкмыйк.
Безнең өчен ул болай да ачык,
Күңел өсләрендә ачыклык...

*** * ***

Кара төнне яңгыр юды,
Агартасы килгәндер...
Изге су белән юсаң да,
Төн агармый дигәндер...

*** * ***

Җәй исен исним-исним,
Бер дә кыш җиле исми...

*** * ***

Кычкыра тиле дөнья чатында:
«Юк ла миннән артык җирегез...
Тарих китабының бер битендә
Миңа да бер абзац бирегез!..»

## Ай

Кара дөмнең тишегеннән
көн яктысы агыла.

Өченче кат

Бер беткәч, кайту юк, диләр дә —
Суварда, Ашлыда, Биләрдә
Җан елый караңгы төннәрдә...

*** * ***

Тарих тулган канлы эзләр белән,

Үткән тулган ялган сүзләр белән,
Күз буяшлар, сүз уйнашлар белән,
Ком сибелгән нурлы күзләр белән —
Тарих тулган канлы эзләр белән.

«Кара козгын» адәм кызганмаган,
Кан эчкәндә җиңен сызганмаган,
Чиксез кеше аңа корбан булган;
Коры кулын ләмгә аз манмаган —
«Кара козгын» адәм кызганмаган.

Үз туганы, иле, үз халкына
Астыртынлык кылган. Ни хакына?
Шайтан белән бергә бәйрәм итеп,
Тап төшерә ул изге антына —
Үз туганы, иле, үз халкына.

Тәмуг төбе, казан асты аңа,
Әнә аның кара җаны яна,
Сыкрый-сыкрый ачы тавыш белән.
Күзләреннән канлы яшьләр тама —
Тәмуг төбе, казан асты аңа.

Тарих чуар кара таплар белән,
Козгын өчен корбан затлар белән,
Билгесезлек белән үткән тулы,
Ялган хәбәр, ялган хатлар белән —
Тарих чуар кара таплар белән.

## Дөреслек

Каты да, ачы да —
дөреслек;
Пычак та, кайчы да —
дөреслек.

Авыр да, җиңел дә —
дөреслек;
Гел йөри күңелдә
дөреслек.

Ялганны җимерә
дөреслек;
Сүз белән күмелә
дөреслек.

Карасаң, барысы
дөрес күк.
Йомырка сарысы —
дөреслек.

## * * *

Кол Шәриф бер,
Илдә берәү генә,
Дөньяда да, бәлкем, берәүдер.

Аны төзү,
Безне, дәшмәс өчен,
Авыз йомдырырга теләүдер.
«Карт» чиркәүләр
Бездә тулып ята,
Яңа калкып килә мәчетләр.
Әйтерсең лә
Без хуҗасыз мәче,
Ә калганнар — блатлы этләр.
Без, татарлар,
Бер тамырдан чыктык,
Нигезләр бер безнең ләбаса.
Кемдер анда,
Пеләш артын куеп,
Җилкәсенә төенчек аса.
Башкортлар да
Безгә каршы төште —
Туралыйкмы вак-вак кисәккә?
Әллә инде
Гасыр азагына
Юкка чыгу безнең исәптә?..
Кубрат үлгәч,
Аның балалары
Вәгъдә тотмый качып беткәннәр,
Ә аларны,
Дошманнары җитеп,
Йомшак бакыр төсле бөккәннәр.

Мишәре дә,
Керәшен, типтәре дә,
Нугайбәге, Касыйм татары,
Үз башында
Аек акыл булса,
«Без аерым!» диеп ятармы?
Чукынасы
Бер дә килми әле,
Тел югалткан балык шикелле,
Маңкорт кебек,
Зомби сыман йөргән,
Төсен җуйган халык шикелле...

...Әгәр бетсәк,
Тузан күтәрелер,
Җиргә ятар Сөембикәбез.
Тату булсак,
Өмет көчле әле,
Дошманлашсак —
димәк беткән без.

## Уян, татар!..

Уян, татар!.. Уян, халкым!..
Күтәрел!..
Бу хәлеңдә бабаң күрсә,
үртәлер.
Алда безне бик күп эшләр
көтәдер,
Татар булсаң, татарлыгың
күтәр бер!..

Йоклап ятма, сикереп төш
ятактан!

Әнә кемдер муеныңа
бау таккан,
Коллык бавы тышаулаган
һәр яктан,
Үкенечләр елап калды
ерактан.

Аңыңа кил, күзеңне ач,
татарым!
Сүзсез башың иеп тору
хатадыр.
Безне көтеп алда ал таң
атадыр...
«Бу — татар!» — дип, үзеңне бер
аталтыр...

Милләт төсен җуйган халык
бетәдер,
Хөр әләмең зәңгәр күккә
күтәр бер!
Кара пәрдәңне алып ат,
челтәр эл... —
Уян, татар!.. Уян, халкым!..
Күтәрел!..

## * * *

Бәхетле илнең баласы
Бәхетсез булаламы?
Бәхетле ил кайда соң ул —
Хыялга уралганмы?..

## Юнәлеш бирү

Тегеләй ит, болай ит,
Түбән төшер, өскә менгер,
Уңгарак бар, сулга кит —
Әнә теге төштә Себер!..

## Сала теле

Кала теле түгелсең син —
Сала теле.
И бүленмәс һәм сер бирмәс,
Ана телем.

Авыл саклый синең тирән
Тамырыңны.
Ә шәһәрдә... «Явыз Иван»
Ябырылды.

Сабыйларың урыс теле
Кочагында.

Кара бөркет үз нотыгын
Куша монда.

Ялгыз калган Робинзондай
Бүген хәлең.
Кая синең горурлыгың
Һәм мөнбәрең?..

Кая синең күкрәк киереп
Йөргән чагың?..
Кая синең төркилегең?..
Кая чаңың?..

...«Әннә», — диеп ачылмаса
Сабый теле,
Киләчәктә кем аңлар соң,
Телем, сине?..

## Барыбыз да бер гамьле...

Барыбыз да бер гамьле —
Безнең татар бердәмме?
Милләтебез ихласмы?..
Күздән йокылар качты.

Еллар болай да изде,
Тынгысыз күңел сиздe:
Нигә без таркау кавем,
Үз ягыбызга тартмыйбыз
Ник тарихның үлчәвен?..

Әй татар, татар, татар!
Бу көн кем йоклап ятар?!
Күзеңне ач тагы да —
Син бөркет тырнагында.

Чәбәлән, тартыш, тырыш,
Тарих үлчәвен борыш,
(Читләр ягына түгел!) —
Үзеңдә үссен бу гөл!..

Күкләр авызын ачты,
Күздән йокылар качты:
Барыбызда да бер гамь —
Бул, татар, тату, бердәм!..

## Татар моңы

Күңел тулган чагында,
Моң-хисләр кочагында
Җилпенеп очам гына

Исереп моң-көйләрдән...
Җыр агыла Болгардан,
Җыр агыла Биләрдән...

Туктаусыз моң агыла
Чал тарихтан, үткәннән.
Әби-бабай күңелендә
Алар зур юл үткәннәр,
Ак болытларга әйләнеп,

Безгә килеп җиткәннәр.

Тарих иләкләре аша
Узган җырлар күккә аша.

Йөрәкләрне кубара моң,
Күңелләрне өзеп ала,
Үзе карт ул, үзе бала.

Үткәннәрдән килгән моңнар —
Бабайлардан калган мирас.
Нәсел аша күчкән алар,
Миндә дә бар алар бераз.

Моң касәсе тулар-тулмас,
Аннан эзлим, моннан җыям.
Һәрбер энҗе җыр тамчысын
Күңел китабыма уям.

Ятим булмас, күчәр алар
Бабайлардан оныкларга.
Татар яши — моңы яши,
Тарих күк, чал болытларда.

## * * *

Кошлар китә, кошлар кайта,
Җәйләр үтә, җәйләр җитә.
Кире кыңгыр эшләр кайта
Язгы җилдә, язгы җилдә.

Яшәгәннәр югалмыйлар,
Исемнәре калкып чыга.
Тарих ташын юалмыйлар,
Сүнгән йолдыз балкып чыга.

## * * *

Дала җиле килеп хәбәр бирә:
Болгар, Биләр, Сувар, Җүкәтау...
Елак бала булып төшкә керә
Гасыр күмгән шушы һәр атау.

## Үткәннән килгән өн

*Суда йөзә бүрәнәләр,*
*Ялгыз бүрәнәләр...*

Кайда син, Болгарым, Кашаным?..
Кайда син, Биләрем, Суварым?.. —
Җиде төн уртасы җиткәндә,
Бу хакта күкләрдән сорадым.

Ерактан, үткәннәр иленнән —
Чулманнан, Агыйдел, Иделдән

Өзелер-өзелмәс өн килде:
«Без күптән бу җирдә юк инде...

Төзедек Урдасын, ханлыгын,
Тау итеп калдырдык байлыгын.
Кая ул без салган мәмләкәт? —
Үткәндә — һәлакәт, һәлакәт...

Казанны илбасар алганда,
(Юк сезнең акланыр хакыгыз!)
Ханбикә, Үтәмешгәрәйне
Кәнизәк иттегез, саттыгыз.

Урыска калдыгыз уллыкка —
Сез хәзер биш йөз ел коллыкта,
Без хәзер биш йөз ел коллыкта...
Безнең рух кайгылы, борчулы,
Каршыда киселгән кул чугы...

Төзедек Сараен, Үкәген*,
Без сезгә зур дәүләт калдырдык.
Дошманнар мыскыллап көлделәр:
«Үткәнен җимердек, яндырдык!..»

Ерактан, гөл-көлләр иленнән —
Чулманнан, Агыйдел, Иделдән
Сүрелер-сүрелмәс өн килде:
«Сал суда баталмас бит инде...»

## Татар моңына мәдхия

Изрәп яткан төнне сискәндергән
моңлы тавыш мин.
Күңелләргә кергән, җанга сеңгән
ап-ак сагыш мин.

Буыннардан буыннарга күчкән
серле табыш мин.
Җәбер-золымнарны, зарны кичкән
дәртле чабыш мин.

Хөр татарның җаны аша аккан
ап-ак сагыш мин.
Һәр йөрәктә тәкъдир булып яткан
ачы язмыш мин.

## Безнең тарих...

Гомер буе халык кол булмаган,
Күңел ачкан, биеп кул болгаган.
Яшәгән ул — үз-үзенә хуҗа,
Тормышлар бай, күрелмәгән нужа.

Зур дәүләтләр тоткан, хан булган ул,
Очар коштай азат җан булган ул.
Төркиләрне җыйган, Берлек төзеп,
Болыннарда йөргән чәчәк өзеп.

Дошманнарын бик тиз буйсындырган,

Чиркәве дә, мәчете дә торган
Үз иленең һәрбер каласында,
Муллык йөргән һәрбер саласында.

Кызын биреп, үзе кызлар алып,
Яшәп яткан безнең төрки халык.
Тамагы тук, өсте бөтен булган,
Еллар үткән, бар да төтен булган...

Дуслык беткән хәзер төркиләрдә,
Таркалган ул вак-вак хөр илләргә.
Дошманнары шуны көтеп торган,
Кылычларын кайрап, сөртеп торган.

Берлек дигән аять югалганда,
Илбасарлар көлеп торган алда.
Бер-бер артлы җиңгән төркиләрне,
Буйсындырган вак-вак хөр илләрне.

Җилгә очкан байлык олау-олау,
Безнең халык кигән тимер богау.
Читлектәге сандугачтай хәле,
Көчләнгән ул, аннан таккан тәре.

Мәчетләрдән калган хәрабәләр,
Читкә киткән алтын-гәрәбәләр.
Тамаклар ач, өсләр ертык-портык,
Һәр җирдә ул ятим, ялгыз, артык.

Кая инде биеп куллар болгау,
Биш йөз еллап кулда чуен богау.
...Эх, яшисе иде Берлек төзеп,
Киң болында йөреп, чәчәк өзеп!..

## Татарлык

Йөрәктә моң булып ятарлык,
Күңелдә гөл булып атарлык —
Татарлык!
Татарлык!!
Татарлык!!!

Кысса да тыныңны тар тарлык,
Хакың юк диңгездә батарлык —
Татарлык!
Татарлык!!
Татарлык!!!

## Казан — Әстерхан поезды

Казан — Әстерхан поезды
ашыга, чаба,
ашыгудан, ашкынудан,
ашалган рельсларга
гүя ут каба.
Оча поезд азат бөркет сыман,
тирә-якта урман әле, урман...

Казан салкын иде, ерак Әстерханда
эссе челлә, диде кемнәрдер,
ул кешеләр ачык белгәндер лә —
Казан гына суык нигәдер...

Казан — Әстерхан поезды
йөгерә генә,
кан тамыры күк рельслардан
бара-бара уйга тала,
ул ачык белә:
Ата-баба җире буйлап чаба,
артта боек Сары таулар кала...
Ә күңелдә курку-мазар тамчы да юк,
соң, туганнар, безнең җирләр бу,
борынгылар безгә васыять иткән,
без югалткан гүзәл илләр бу!..

...Казан — Әстерхан арасы —
татар яшәгән урын.
Колак кактык бу байлыктан,
без кулга алмас борын.

Җир безнеке, ә кануннар
безнеке түгел инде.
Азат еллар, көлгә әйләнеп,
кара туфракка сеңде.

Куе урман, киң далалар...
Иделкәй, Каспий диңгез...
Без нишләр идек синсез...

Казан — Әстерхан поезды
йөгерә генә...
Ярый әле рельслар бар,
үткән салган рельслар бар,
юанычтай куна бәхет
кайгы бөдрәсенә...

## * * *

«Бие, бие, бие!» — дисез,
биемим.
Әнә шундый кире беткән
инде мин.

«Җырла, җырла, җырла!» — дисез,
җырламыйм.
Эндәшмәгез, сүзегезне
тыңламыйм.

Бу сүзләрнең тамчысы да
хак түгел.
Күңел ачып йөри торган
чак түгел.

Бәгырьләрне таптап уза

замана.
Хуҗа безгә «тәмле телле»
тамада.

«Биетә» дә, «җырлата» да,
«көлдерә».
Үзе күзгә карап төтен,
көл өрә.

Шәп булыр да тамадага
күз тисә...
Ул ялганнан, ул фальштан
күз кисә...

...Булмаса, бер елыйм әле
туйганчы.
Күз яшьләрем ялган көлне
юганчы.

## Тулгак тота мине...

*Чын күңелдән көрәшергә*
*Тулгак тота мине...*
Гамил Афзал

Бертуктаусыз исеп тора
Салкын шималь җиле.
Дөньясына корым каткан,
Тормыш тиле-миле...

Һәр чат саен хәер өсти
Сәрхуш татар ире...
Ук атылган... болгатылган
Данлы татар иле.

Урыс тамагын туйдырып,
Чыкты соң җан тире!..
Үткәннәргә алып кайта
Канлы тарих җире...

Сөйләшеп хәзер ни файда,
Югалтабыз сине!..
Чын күңелдән көрәшергә
Тулгак тота мине...

## * * *

Керләнгән күңелне
Пакьләргә теләпме,
Акларга теләпме
Битараф йөрәкне...
Кар ява ничә көн,
Кар ява атналар...
Гөнаһсыз дәверләр
Кар булып кайталар.

Тутыккан кылларга
Чиртергә теләпме,

Җандагы төерне
Тамакка терәпме...
Кар ява ничә көн,
Кар ява атналар...
Илаһи көн җирдә,
Илаһи тантана!..

Таш бәгырь өстенә
Әфсеннәр көйләпме,
Ап-ак кар йөрәктә
Ак ялкын көйрәтте...
Үткәннән иң садә
Мизгелләр кайталар...
Кар ява ничә көн,
Кар ява атналар...

## Уфага барганда...

Илешкә кердек. Каеннар
Кинәт үз төсен җуйдылар.
Бөтенесе бер сулыштан
Татарлыгымны тойдылар.

Каеннарга: «Саумысез!» — дим,
Алар миңа: «Һаумы!» — диләр. —
«Һай, бик авыр күтәргергә
Җилкәдәге тауны», — диләр.

Карыйм — башкорт каеннары,
Бер күз салсаң — татар кебек.
Каеннарның кайрылары
Кинәт моң-яшь атар кебек.

Агачларның ботакларын
Тынгысыз җил капшап тора.
Салкынлыгы, туңы белән
Кәүсәләрен ашап тора.

Ак каеннар: «Өстебезгә
Олы хәсрәт ауды», — диләр...
Күңелем сизә, алар миңа
Эчтән генә: «Саумы!» — диләр.

## Тарих

Кыяга чокылган эзләрне
Диңгез дулкыннары юа.

## Даһи гомере

Күкне ярып үтте
очкыч,
Туң диңгезен өтте
очкыч...

...Ко-точ-кыч!!!

## Татар яшьләре гимны

Бездәге горурлык
Мең затка торырлык,
Бездәге горурлык җитәрлек.
Халкыбыз өчен лә,
Ут-ялкын эчендә
Барырбыз тауларны күтәреп.

## Икенче кат

Эһем-эһем, әт-тәт-тә,
Менә юмор нишләтә —
Файдасы да бишләтә!..

## Яшәеш

Энергияне саклыйлар
Сәгать телен күчереп,
Газны, утны, җылылыкны,
Кайнар суны сүндереп.
Үзләренчә шәп ясыйлар —
Ярты нервыны ашыйлар
Шушыларга күндереп.

## Сорап тормады...

*Галимҗан Гыйльмановка*

Кырыктан соң миңа проза килде,
Биксез ишегемне ачып керде,
Җылы кочагына урады,
Сөйгәнемнән сорап тормады...

...Төренгәнмен сөю учагына,
Хәзер ятам проза кочагында,
Ә ул мине назлый, коча гына...
Ярым гына берни кылмады,
Кая китте? — Әйтеп тормады...

## Оялам

«Мин сине яратам», — дисең,
чынлап микән?
Әллә инде сөйләшәсең
уйнап микән?

Күзләрең — күл, кашың — камыш,
серле үзең.
Ә иренең — кызыл чия,
нурлы йөзең.

Елмаясың аска карап,
сискәндереп,

Синең яннан иркә җилләр
искән кебек...

Сүзсез генә басып торам
читкә карап —
Кочагына тартып алса,
эшләр харап!

Йөрәгемә «сердце» булыр
ул чагында,
Эрермен дә югалырмын
кочагында...

...Күзләремне чытырдатып
йомам да мин,
Әллә кая, хыялларга
чумам да мин...

Басып торам, нәрсә дияр
икән хәзер?
Миндә түгел, эх, чукынган,
кыю «козырь».

Оялам мин, беләсезме,
оялам, дим,
Коткар мине, зинһар өчен,
бер Аллам, дим.

Тагын әйтсә шушы сүзен,
кош булырмын,
Кызарырмын, зәңгәр күккә
омтылырмын.

Җир астына төшәрмен дә
тишек табып,
Җилдәй җитез җилдерермен,
китсәм чабып...

Оялам мин, панимаешь,
каты гына.
Кызлар кочу кая инде,
какуй миңа!

Уйланамын шулай гына...
...Күзне ачсам —
Теге кызый оялудан
үзе качкан!

## * * *

Син дә сәнгать кешесе лә,
Мин дә сәнгать кешесе... —
Син — халык шагыйренең, һәй,
Мин — артистның күршесе...

## Юл буйлап килә иркәм

Көнбагыш чиертә-чиертә,
Юл буйлап килә иркәм.
Сокланып карап торам,
Ә үзем авыз ерам:

«Нинди чибәр, нәфис, ах!
Күңеле тулы хис, ах!
Күзләре саф, чиста уй,
Метр сиксән анда буй.

Шәп хатын булыр бу, шәт,
Торам тәрәздән күшәп.
Минеке кыз, шөбһәсез,
Ярым булыр үпкәсез».

...Лач-лоч чәйнәп сагызын,
Иркәм килә ялгызы.
Күз алмый карап торам,
Ә үзем авыз ерам:

«Мини итәк — килешле,
Причёскасы — үлешле.
Иреннәре гел иннек —
Аягүрә үләрлек!..

Шәп хатын булыр бу, шәт,
Торам тәрәздән күшәп.
Минеке кыз, шөбһәсез,
Ярым булыр үпкәсез».

...Тәмәкесен суырып,
Сыра белән юдырып,
Юл буйлап кайта иркәм,
Чайкала алпан-тилпән.

Каш җыерып карыймын,
Бармак селкеп яныймын:
«Юньсез, юлдан язгансың,
Азгансың син, азгансың!

Кемне интектерерсең,
Кемгә бил бөктерерсең?..—
Килә дә күрмә якын,
Кирәкми синдәй хатын!»

## Бирерләр микән?..

«Бар,— дип,—
синдә Афзаллык»,
Тоттырдылар абзарлык.

«Бар,— дип,— синдә Юзилек»,
Чыгардылар бер өйлек...

...Бар бит әле Ленарлык! —
Бирерләр микән, Ходаем,
Остазларны сыйларлык?..

## Мин — кыска, мин — озын

*Мин — мәзәк шикелле кыска,*
*Әкият кебек озын.*
Газинур Морат

Әллә нәрсә булды миңа,
Әллә чир, әллә бозым? —
Мин — помидор төсле кыска,
Кыяр шикелле озын.

Хәләл хатыным өстенә
Бай димли гүзәл кызын.
Мин — фатирым кебек кыска,
Кремль шикелле озын.

Нидер сызгалап утырам,
Аңламый торган сызым.
Мин — тузган каләмдәй кыска,
Өр-яңасыдай озын.

Шигырь чыкмый дигән булып
Борчылмыйм, ә син тузын.
Мин — киви шикелле кыска,
Банан шикелле озын.

Беркайчан да сүнмәс, ахры,
Йөрәктәге моң кузым...
Иҗатым төсле озын.

## Бар бездә берәү!

Группада унберәү,
Арабыздан тик берәү
Ия кадер-хөрмәткә —
Яраталар, әлбәттә!

Кулда гына йөртәләр,
Тими янау, шелтәләр.
Асылташтай ул затлы!
Аһ андагы тыйнаклык!

Группага бер ай сыман
Һәм кояшлы май сыман!..
Кем ул? Әйдә, уйлагыз,
Уегызны тыймагыз!

Группада унберәү...
Малайлардан мин берәү!
...Яратам унның берсен...
Әйтмимен, белми йөрсен! —

Юкса калган тугыз кыз
Мине яратмый башлар,
Оҗмахтан утка ташлар.

## Талант

Радиосын кабызып,
Телевизорын карап,
Караватта гәзит укыйм —
Менә мин нинди талант!..

## Декан буласым килә!..

*(Беренче курс студентының хыяллары)*

Җитәкчелек эшенә мин
Туганнан алып гашыйк.
Ник җылы урын бирмиләр,
Күптәннән көтәм шашып?..

...Староста иттерсәләр,
Нишлисен беләчәкмен! —
Каршы әйткән шалапайның
Кирәген бирәчәкмен!..

Культорг итеп куйсалар,
«Татфак» шаулап торачак!
Минем канатым астында
Үрләр яулап торачак!..

Профорг булсам, акчаны
Каерып алачак мин!..
Биш курс типтереп йөргәч,
Өч елга калачак мин!..

Кыяфәтем коеп куйган,
Сокланамын көзгегә:
Аспирант, доктор, профессор
Булачак мин тиз генә...

...Артка гына типмәсеннәр —
Декан буласым килә!..
Һич югы, теләк үтәүче
Чуртан буласым килә!..

## Ярты-ярты... Киңәя?!

*Синең кулда ярты алма,*
*Минекендә — яртысы.*
*Бәхетләрем ярты-ярты —*
*Ничек кенә ялгыйсы?*
Рәмзилә Хөрмәт

Синең кулда ярты чалбар,
Минекендә — яртысы.
Миндә өч кенә чемодан,
Синдә исә — алтысы.

Синең кулда ярты шкаф,
Минекендә — яртысы.
Күңелемдә кышкы котып,
Синдә — Кырым Ялтасы.

Синең кулда ярты диван,
Минекендә — яртысы.
Күршеләрдә бәхет-шатлык,
Бездә — мөлкәт тартышы...

Синең кулда ярты байлык,
Минекендә — яртысы...
Ай-яй, киңәя түгелме

Алиментлар картасы?!

## Гомер буе шуны аңлатам...

Сызылып киткән ул кашларың өчен,
Тәмле-тәмле сый-ашларың өчен,
Энҗе-мәрҗән, ак ташларың өчен,
Карашларың өчен яратам.

Кочагымда җебүләрең өчен,
«Имансыз!» — дип сүгүләрең өчен,
Блузкаңдагы чигүләрең өчен,
Үбүләрең өчен яратам.

«Матурым!» — дип сыйлауларың өчен,
Телең белән кыйнауларың өчен,
«Сөя»,— диеп уйлауларың өчен,
Елауларың өчен яратам.

«Бар, кит!..» — диеп сөрүләрең өчен,
Эндәшмичә йөрүләрең өчен,
Мине якын күрүләрең өчен,
Көлүләрең өчен яратам.

Уттан суга салуларың өчен,
Гамьнән тартып алуларың өчен,
Мине эзләп табуларың өчен,
Януларың өчен яратам...
Гомер буе шуны аңлатам.

## Карлы Маркс урамында...

Карлы Маркс урамында
Карл Маркс йөренә,
Ә ерактан кепка кигән
Бөек Ленин күренә:
— «Капитал»ың үлде лә...
Маркс иптәш-әфәнде,
Яңарттылар ич фәнне,
Үзгәрттеләр илләрне —
Борчылдым да чирләдем.
Без дә тиз юкка чыктык...
Уйлыйлардыр: оныттык?!
— Әйе,— диде Карл Маркс,—
Дөрес әйтәсең... Такс...
Безнең уйча булмады,
Дөнья тотып кыйнады.
Сталин мескен бүлнистә,
Ул хәзер үлде исә...
Энгельс, сәрхуш, запойда —
Түзәм инде бу айда,
Тарта башлады үлән,
Танымыйм аны, үләм!..
— Әйе шул,— диде Ленин,—
Асылынды Есенин,
Атылып үлде Маяк.
Хатында протез аяк,
Унбер каттан сикерде...
— Ни сөйлисең, кит инде?!
Нәрсә эшли җефетең?
Тешләде әллә этең?..

— Юк,— диде авыр сулап,
Әйтерсең ярдәм сорап,
Ленин бакты дустына.
— Ни үтенеч, куш кына...
— Наркоман ич хатыным,
Күгәрде бит алтыным.
Әллә нәрсә безләрдә,
Нурлар кипте күзләрдә;
Ил дә таркалып бара —
«Аврора» батып бара...
Халык безне онытты.
Кем җиңелде? Кем отты?..
Тәрбия — сынык аяк,
Ә намус — коры таяк.
Әдәпнең кулы тайган...
Ярлы катлау һәм байдан,
Төрле-төрле катлаудан,
Эре һәм вак атлаудан
Төзелгән тормыш-баскыч,
Ярамый алтын ачкыч...
— Әйе шул,— диде Карл,—
БМО, безгә борыл!!!
Ә ул дәшми, ул сүзсез —
Аңа бөекләр төссез,
Алар — үткән-киткәннәр...—
Заманаы сүткәннәр...

Карлы Маркс урамына
Әкрен генә кар төшә.
Ленины да, Марксы да
Хәзер Марска күчә.

## Без карт идек...

*Без яшь идек...*
Лилия Гыйбадуллина

Без карт идек...
Сүлпән кояш идек,
Кышкы ак кар,
Туңган боз идек.
 Япь-яшь кызлар,
Мәхәббәтле кызлар
Гашыйк итте,
Шуңа бозылдык.

Без карт идек...
Хәзер без яшь инде,
Күңел чыклы,
Күңел чыланган.
Егетләрдәй очып
Чыгып киттек
«Картлык» дигән
Кара чоланнан.

Без карт идек...
Хәзер без яшь инде,
Йөрәк сөя,
Йөрәк сөелә.
Яшь кызларның
Җылы кочагында

Картлыкның да
Башы иелә...

## Ходаймы шулай кушкан?

Ходаймы шулай кушкан? —
Син — мәче, ә мин — тычкан.
Эчемдә давыл булса да,
Сиздерми йөрим тыштан.

Язмышмы шулай корган? —
Син — ерткыч, ә мин — корбан.
Син аулаган тычкан халкы —
Исәпләп булмый торган.

Аңлый алмыйм һич кенә —
Син — олы, мин — кечкенә.
Минем күңелдә изгелек,
Синекендә — үч кенә.

Уйлап куямын кайчак —
Син — тиран, ә мин — качак.
Алдыңда сөт, каймак... Ә мин
Йөрим булганын ашап.

...Торам әле баш кашып —
Син — сөйгәнем, мин — гашыйк.
Дуслашыйк, йә, корбан ит —
Мәңгелеккә хушлашыйк.

## Язышучы

Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр...
Шыгырдата кәгазьне.
Сызып-бозып әрәм иткән
Кәгазь битләре әзме?..

## Миндәй кешегә...

Матайдан да очкан бар,
Кызларны да кочкан бар.
Матай, кызлар — «чүп» икән ул,
Өй базында тычкан бар.

Төн йоклатмый хәшәрәт,
Йокламагач, кача рәт.
Матай, кызлар уйда да юк —
Ярдәм итми тәһарәт.

Битне дә юып карыйм,
Күзне дә уып карыйм.
Йокы туймагач, әйт әле,
Мин соң кайларга барыйм?..

Алып кайттым бер мәче,
Авылда ул иң яше.
«Тынычландыңмы соң, туган»,—
Дип соранып йөрмәче...

Берсе такта кимерә —

Симергәннән-симерә.
Икенчесе дөбер-шатыр
Базда нидер җимерә.

Сүкмим дә, янамыйм да,
Матайга карамыйм да.
Кызларга ошыйм әле дип
Чәчемне тарамыйм ла...

Аңламасын бирсе дә —
Кунам хәзер күршедә.
Үз өендә үз көе юк
Миндәй юаш кешегә.

## Гашыйк җан

Синең янда утырам мин
Мунчадан чыккан кебек:
Тирләп-пешеп,
Кызып-өшеп,
Авыру йоккан кебек.

Синең янда утырам мин
Яңадан туган кебек:
Яңа шыткан,
Төртеп чыккан
Кыюсыз суган кебек.

Синең янда утырам мин
Нәп-нәни куян кебек:
Өркә-өркә,
Йөрәк кәтә —
Үләм дә куям кебек.

Синең янда утырам мин
Эндәшми-тынмый гына...
Мәхәббәт мәхәббәт инде —
Гашыйк җан тыңлый гына.

## Студент монологы

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр китаплар.
Йоклау, ашау, әз-мәз уку —
Без үтәсе этаплар.

## Тигезлек эзләгәндә...

Башыбыздан ашкан иде җир салымы,
Хатыннарга керткәннәр, ди, ир салымы.

Биш елга бер вакытында түләсе, ди,
Соңга калсаң, егылыплар үләсе, ди.

Түләмәсәң — син ireңнән колак какмыш,
Идән төеп һәм кычкырып елап ятмыш...

Хатыннарның күңелендә борчу артты,

Күпме салым өя дәүләт бер-бер артлы:

Йорт өчен дә, кош өчен дә, ат-сыерга,
Газиз башка төшә бар да бик кыенга...

...Думадагы хатыннар күп сүзләр йөртмәк —
Хатын тоткан ир-атларга салым кертмәк.

## Әңгәмә

— Йөзең көләч, кәефең шат —
Гашыйк булдыңмы әллә?..
— Ун кыз миңа: «Сөям!» — диде,
Көлмәле, әзрәк җәллә.

## Бер гомеркәй җитми икән!

Туганда ук укып туган,
Ашамаган кишер-суган,
Тәпи йөреп китү белән
Гыйлем куган, гыйлем куган.

Кояштан ул сер эзләгән,
Төнлә йолдызлар күзләгән,
Көн укыган, төн чокынган —
Тик тормаган — җан түзмәгән.

Урамнарда җил кумаган,
Ашамаган, бит юмаган,
Айга менгән, диңгез кичкән —
Бу дөньядан аң юллаган.

Китаплары өем-өем,
Еллап чишкән бик күп төен,
Карамаган өстен-башын,
Җимерелеп барган өен...

Малай иде, хәзер — бабай,
Ахирәткә калган бер ай,
Әҗәлгә дә исе китми —
Мең яшәргә әзер бабай...

...Безнең гомер чикле икән,
Укысаң да, бетми икән...
Аң-гыйлемне өйрәнергә
Бер гомеркәй җитми икән!

## Мин сине озак эзләдем...

Мин сине озак эзләдем...
Вокзал тирәләреннән,
Базар тирмәләреннән...

Мин сине озак эзләдем...
Китап киштәләреннән,
Язгы җил сәламеннән...

Мин сине озак эзләдем...

Шомлы шәһәр шавыннан,
Айның кул болгавыннан...

Мин сине озак эзләдем...
Трамвай тукталышыннан,
Болытлар агышыннан...

Мин сине озак эзләдем...
Өмет өзелгән мәлдә,
Син ялтырап ята идең
Бакчадагы түтәлдә...

Мин сине озак эзләдем...
Юк иде тиенгәнем —
Бер тиен сөенгәнем!

## Юк арды

Кая китеп
югалдың?
Күңелемне
юк алды.

Юк, юк, юк, юк...
юк калды...
Көтә-көтә
юк арды.

Уйлап җыен
юк-барны,
Вакыт булып
юк барды.

Юк, юк, юк, юк...
юк калды:
«Кая китеп
югалды?..»

Көтә-көтә
юк талды.
Мин армадым,
юк арды...

## Костюм кияргә микән?

Вакыт-вакыт күз төшерәм
Костюмың, чалбарыңа...
Килергә дә куркам хәзер
Мин синең яннарыңа.

Карашларың җитди-җитди,
Кыяфәтең — акыллы.
Сине күргән егетләр дә
Бер тавыштан «аһ» орды.

Читтән торып караганда,
Мөгаллимә кебек син.
Аспирантура бетергән
Бер галимә кебек син.

Депутат кыз шикелле син,

Җитәкче «апа» сыман.
Тик костюм, чалбар артында
Гади кыз ята сыман...

...Ут капкандай чабар идем
Мин синең яннарыңа...
Йон кабара, күзем салсам,
Костюмың, чалбарыңа...

...Телне тешләп карап торам —
Нәрсә дияргә икән?..
Синең янга килер өчен
Костюм кияргә микән?..

## Киңәш

Ике икең — дүрт була,
Кар күп яуса, көрт була.
Кызларның «Бар, кит» дию
«Бераз гына көт» була.

## Күпне белсәм...

Мин гармунда уйный белмим,
Гитара уйный белмим.
Биек бөекләр шикелле
Зур уйлар уйлый белмим.

Мин оста җырчы да түгел,
Оста шофер да түгел.
Кыяфәткә караганда
Артык шәп ир дә түгел.

Мин нәфис сүз сөйли белмим,
Көйләр дә көйли белмим.
Кешене, тәлинкә тотып,
Җайлый да көйли белмим...

Мин гади бер шагыйрь генә,
Кулымда каләм генә...
Күпне белсәм, макталудан
Булырмын әрәм генә.

## Ярсу

Сөя, сөйми... сөя, сөйми —
Йолкыйм ак чәчләремне.
Пеләш калып бетәм инде,
Тыңлап эндәшмәвеңне.

## Шаяртам

«Әшәке син», — дигән булып
Шаярткан буласың бит.
Үзең һаман мине үлеп
Яраткан буласың бит.

Кайчагында: «Бар, кит!» — диеп
Ачуланган буласың.
«Сөйләшмә, эндәшмә — җитте»,—
Дип кыланган буласың.

Сүгәсең дә, тиргисең дә,
Аннан: «Гафу ит...» — дисең.
Кайвакытта шундый шаян,
Кайчагында җитди син.

Син шаяртып яратасың,
Мин сүз әйтми яратам...
...«Юри генә бит очыңнан
Үпмим әле...
— Шаяртам!»

## Нишләрмен?..

*Буран иде...*
*Һаман буран дулый...*
*Буран — канат,*
*Буран — хисләрем...*
Лилия Гыйбадуллина

Буран иде...
Һаман буран дулый...
Буран — канат,
Буран — хисләрем...
Ишегемә кемдер шакыр сыман
Кар ураган шомлы кичләрен...

Яңгыр иде...
Һаман яңгыр ява...
Яңгыр — канат,
Яңгыр — хисләрем...
Тәрәзәмә кемдер чиртер сыман,
Өзәр кебек моңсу төшләрем...

Җилле иде...
Һаман җилләр исә...
Җилләр — канат,
Җилләр — хисләрем...
Түшәмемне кемдер төртеп тишсә,
Тынып калыр җилле кичләрем...

Челлә иде...
Һаман челлә тора...
Челлә — канат,
Челлә — хисләрем...
Идәнемә салкын сулар сибәм,
Кемдер шытып чыкса нишләрмен?..

## Акча әйләнеше...

Киштә-киштә аракылар,
Өем-өем сыралар.
Коньяклары, шәраблары
Кызыктырып торалар.

— Абзыкаем, алып җибәр, —
Ди сатучы. — Салып җибәр...

— Апа, әйдә, бер акны ал,
Йә булмаса коньякны ал!..

Төкер әйдә дөньясына,
Дөньясы — эт оясына!..
Эчә-эчә туганбыз без,
Башта тәпи юганбыз без...

Тормышыбыз эчә-эчә,
Алга бара күчә-күчә.
Туган көннәр, юбилейлар,
Һәр датада юбилей бар.

Бакча, мәктәп, чыгарылыш,
Яшәү рәхәт, яшәү кырыс...
Институт, тулай торак —
Монда бәйрәм уңайлырак.

Өйләнешү, бәби туе,
Кеше эчә гомер буе...
Мең кышлый да, мең җәйли ул,
Коры җирдән бөкәйли ул...

Гомеребез бара шунда,
Шешә тавы арасында...

* * *

Күбәләккә дусты иркәләнә,
Чәчәк белән чәчәк серкәләнә —
Нинди сөю, нинди мәхәббәт!.. —
Әкәмәт!..

* * *

Авыздагы кәнфит балы
Соңгы тешкә йөгерде...
Кайда соң син, тешле чагым —
Унтугызым, егермем...

* * *

Такы-токы, гарип юллар
Бары Рәсәйдә генә.
«Евростандарт»ка керәләр
Бары тик җәйгә генә.

* * *

Сандыгында әби кыштыр-кыштыр,
Күңелендә аның салкын кыштыр.
Бабай төшләренә, менәтерә,

Ямьле язлар, япь-яшь кызлар керә.

## Үпкәлимен...

Мин сине көткән идем,
Килмәдең, үпкәлимен.
...Артык курыкма, иркәм —
«Пәп-пәп, пәп-пәп, пәп!» итәм.

## * * *

Җәйгә генә аерылдык,
Мине онытмадыңмы?
Гел-гел сине уйлап йөрдем —
Очкылык тотмадымы?

## * * *

Җан җылыңны
Көтеп яткан чакны
Кочагыма
Песи килеп ятты.

## Беренче кат

Еллар үтә, еллар ага,
Әллә атлый, әллә чаба
**Алга — киләчәккә таба...**

## Нәрсә әйтим?

*(Поэма)*

*Чечен сугышына каршы*

Хатыннар тол,
Бала ятим.
Бу дөньяга
Нәрсә әйтим?

Лачын егет
Башын сала
Ач сугышта...
Ялгыз ана.

Сыкрый ата:
«Бердәнберем!»
Елый ана:
«Йөрәк яна!..
Кисә кайгы
Телем-телем...»

Кемгә кирәк
Кара сугыш? —
Өстән фәрман:
«Тала!.. Сугыш!..
Кеше кырыш!..
Тырыш, тырыш!..»

Шартлый йортлар,
Ява туплар.
Елый сабый:
«Ән-и-и! Абы-ы-й!!!»

И нарасый,
Еламачы.
Вәхшиләрдән
Ярдәм көтмә,
Сорамачы...

Каччы тизрәк,
Чап син, чап, чап!
Үз халкыңны
Эзлә, тап, тап!

Аерылма,
Каерылма!
Сынмасын дим
Канатларың.
Син күп күрдең
Кан тапларын...

...Ялгыз карчык
Буш аланда.
Күзе сукыр,
Сыкырана:

«Каһәр суксын
Бу сугышны,
Бу буышны!
Баш «бөркетне»
Алла суксын!
Тәмугларга
Илтеп тыксын!

Күп уйнады
Җаннар белән,
Сату итеп
Каннар белән.

Чукынгыры,
Дөмеккере!
Минем әле
Җаным тере!..

Картым үле,
Улым гарип.
Тынычлыкны,
Аллам, бар ит!

Бу кирәксез
Суеш, буыш.
Бетсен иде
Каһәр сугыш!..»

Җилләр исә,
Көннәр үтә.
Сугыш бара,
Язлар җитә.

Күпме лачын
Башын салды.
Күпме ана
Телсез калды.

Рухи яра
Кемнәрдәдер.
(Тормыш бавы
Юләрдәдер...)

Кем — абыйсыз,
Ә кем — улсыз —
Кемдер калды
Ике кулсыз.

Нәрсә булды
Дөньяларга? —
«Кара бөркет»
Оялаган.

Тургай да тын,
Тынган урман.
Ә далада
Чаба кылган.

Гомер бара,
Сугыш бара.
Йөрәкләрдә
Төзәлмәслек
Тирән яра.

Күпме лачын
Башын салды.
Күпме ана
Телсез калды.

Хатыннар тол,
Бала ятим.
Бу тормышка,
Бу сугышка
Нәрсә әйтим?..

## Йолкынган тамырлар

***Автордан:** Татарстанның Актаныш районы җирлегендә Өшәр һәм Чиялек (Иске һәм Яңа Семиостров) авыллары булган. Түбән Кама ГЭСы төзелгәч, су басу куркынычы бар дип, аларны көчләп күчерү сәясәте башланган. Ике авыл да беткән, ләкин Өшәр җирлегендә һаман да бер хуҗалык яши, берәү йорт салырга җыена, тагын күчәргә теләүчеләр бар. Ә су әле дә килми.*

Тамырлар йолкынган,
Керфеккә көл кунган.
Чүп баскан учаклар,
Җилне кем кочаклар?
Кем карар офыкка?..
Ай балкый тик юкка?..
Җан асрый бер өйчек,
Торала ул ничек

Ялгызы шушында?..
Җәен дә, кышын да
Тәрәздән шәм балкый —
Янармы ул бакый?
Сүнәрме бервакыт,
Ни эшләр бу ак ут...
Тик әле ул яна,
Эри дә, яшь тама...

Бер йортлы бу авыл...
Ялгызы бик авыр
Яшәве далада,
Йөз яшьтә ана да,
Малае җитмештә,
Берүзе гел эштә...

Бер учак талпына,
Яшәргә ашкына.
Йолкынган тамырлар
Шытарлар, сабырлар —
Киләчәк өметле...
Авылны кем этте,
Таркатты, турады?..
Кемнәрдер сорады:
«Калыйкчы, китмик»,— дип;
«Нигезне биклик»,— дип
Ашыкты кемнәрдер.
Аларны күмгәндер
Гасырлар тузаны...

Йөрәкләр кызамы
Авылны сагынып,
Шул якка табынып?..
Ни тота, күч кире,
Кил якын, кил бире!..
Сүнмәсен учаклар,
Җирне кем кочаклар
Тар кыллар өзелсә?..
Яңа йорт төзелсә,
Өметләр кабыныр,
Җан нуры ябыныр
Өшәр һәм Чиялек
Булмасын беркайчан
«Беткәннәр!» — диярлек...

Тигәнәк, кычыткан,
Әремнәр дә шыткан —
Иртә яз килгәнме?..
Ямь-яшел чирәмле
Садакның буенда
Аккошлар җыенда...

Тамырлар корымас,
Ташларга орынмас,
Керфектән күл китәр,
Бу җирдә гөл үсәр.
Чиялек һәм Өшәр
Терелер, җанланыр,
Ай балкыр аннары.

Йөрәктән нур тамар,
Ул дөрләр, ул янар,
Язларга сөенеп.
Авыллар балкырлар,
Чәчәккә төренеп.

ГАМИЛ АФЗАЛГА

*(Цикл)*

## Җырлы биштәр асып...

Җырлы биштәр асып Гамил килә,
Авылына карап туп-туры.
Үзе көйли нидер, үзе көлә,
Йөрәгендә аның моң тулы.

Өянкеләр аны каршы ала,
Шаулый-шаулый җәйге шат җилдә,
Ботагына җырчы кошлар сара,
Сайрый алар таныш хөр телдә.

Арыш башаклары шыбырдаша,
Яшел үлән исе тирбәлә.
Ап-ак ромашкалар гүя дәшә,
Чая кыздай шаян көлә дә.

Гамил килә җырлы биштәр асып,
Авылына менә тау буйлап.
Яшьлегенең капкаларын ачып,
Атлап керә сакчыл һәм тыйнак.

Үз баласын танып алды шунда
Чәчләре чал, бөкре карт тупыл,
Әйтә сыман үзе авыр тында:
«Гамил, улым, яныма утыр!..»

Сәлам бирә шагыйрь тирә-якка,
Ул бәхетле бүген шулкадәр.
Тик өендә кадакланган такта —
Кемнең эше икән?.. Ай, каһәр!..

...Җиргә иңгән өйнең түбәсеннән
Төтен чыга тышка нур булып.
Якты тәрәзәнең өс-астыннан
Шигырь ага Җиргә моң булып.

## Югалган нигез

Бу нигездән хәзер таш юл үтә,
Тапталган ул нигез, изелгән,
Тик, бичара, һаман нидер көтә,
Бер үлән юк, тамыр киселгән.

Кычыткан да, хәтта әрем үсми,
Юкка чыккан йортның урыны.
Ямьле җәйдә ирkә җилләр исми,
Чабуламый әткәй колыны.

Бер тавыш юк, бары бушлык кына,
Үз сабыен көтми берәү дә;
Төн җитүгә, ачы җилләр тына,
Елый нигез ташлы биләүдә,
Тик ишетми аны берәү дә.

## Кайтыр...

Егерменче йортта
Унҗиденче фатир...
Иртән чыгып китте,
Кичкә тагын кайтыр.

Дусларына гына
Китеп баргандыр ул.
Бу көннәрне озак
Көтеп аргандыр ул.

Күпме янып-көеп,
Өйдә ятты кышын.
Язлар аяк басты,
И күңелкәй, очын!..

Күзләргә нур кунды,
Биткә ал йөгерде.
Иреннәрдә кабат
Елмаю күренде.

Аягына басты:
«Мин яшәргә тиеш...
Мин язарга тиеш,
Әле исән килеш...»

Каләм, бии-бии,
Ак кәгазьдән чапты.
Кыш буе җыелган
Уй дәрьясы акты.

Ходай бирде сиңа
Талпынырга ирек.
Күз алдында шаулый
Бөре ачкан зирек...

...Иртә белән генә
Чыгып китте өйдән.
Саубуллашып калды
Сары буяу идән...

Дусларына гына
Китеп баргандыр ла.
Сүзләре күп булып,
Кичкә калгандыр ла...

...Егерменче йортта
Унҗиденче фатир...
Кичә чыгып китте,
Бүген
кайтыр,
кайтыр!..

## Кайту

*1959 елда туган авылыма кайткан идем. Нигезебез турыннан берәр үлән булса да эзләп карадым, әмма таба алмадым...*
Гамил Афзал

Кайткан идем өметләнеп —
Бәлки, күчәрмен кире...
Җан тартмаса, кан тарта, ди —
Сагындым, туган җирем!..

Нигезебез күптән сүнгән,
Таныш йортлар күренми.
Бер үлән дә табалмадым —
Ник өметем сүрелми!?

Өянкеләр, алар гына
Малай чагымны белә.
Әй, авылым, җирсеп кайттым —
Ник җил-капканда келә?

Нигә миңа урын юк соң
Бу өйләр арасында?
«Кулак калдыгы» дигән сүз
Йөрәгем ярасында.

Үткәнемнең ишекләрен
Бүген тагын ачам бер.
Атлы арбага утырып
Киткән идек кайчандыр.

Атлы солдатлар озата —
Кубарылуы авыр.
Кешеләре әллә нинди,
Дөньялары болгавыр...

Туган ягым, Уралларда
Сагынып яткан идем.
Сагынганга, еллар үткәч,
Кабат бер кайткан идем.

Әй, авылым, туган авыл,
Ата-бабамнар җире...
Үпкәләмә, кичер, зинһар,
Китәрмен инде кире.

Гомер буена сагынып
Яшәргә язган икән.
Чит тарафка алып китте
Көймәдәге ак җилкән.

Ярый, сау бул, хуш, авылым,
Бәлки, бер күрешербез.
Туган туфракта тәгәрәп,
Елмаеп көлешербез...

...Кайда гына яшәсәм дә,
Күңелем синдә булыр.
Сәламнәремне алырсың —
Хатларым җилдә булыр...
Хатларым җилдә булыр...

# Эчтәлек

Шигърияткә Ленар Шәех кирәк! *Роберт Миңнуллин* ....

**Бишенче кат**

Әгәр син янымда булсаң... ........................
Өч сүз .......................................
«Сине күргән саен җанда...» ......................
«Ян, йолдызым, ян!» — дисең син...» ................
Мәхәббәт ....................................
Мин яратам... .................................
Каян дөньяга килгән без? .........................
Нокта яки... өтер?.. .............................
«Татлы сагышым...» ............................
«Минем күңелем — суыткыч...» ...................
«Синең күзләреңне күрсәм...» .....................
«Ап-ак бәхетләр килмәс...» ........................
Әгәр чынлап яратмасаң... ........................
«Күзләреңә карарга да...» ........................
Соңгы алма ...................................
Бары бер кат... ................................
«Син — якын-тирәдә...» .........................
«Күңелләрем мөлдерәмә тулы...» ..................
«Гамьсез яфрак буйлап тәгәрәгән тамчы кебек...» .....
«Мин бәхеттән үлдем...» ........................
«Йолдызларга сөйләр идем...» ...................
«Сары сагышлар сардылар...» .....................
Миңа үзең кирәк... ..............................
«Төн саен ачып керәсең...» .......................
«Сәбәп тә кирәк түгел...» .........................
Яз җыры .....................................
«Синсез яшәү бик тә авыр миңа...» ................
«Сүрелдем, оныттым...» .........................
Күңелкәең китмәсме эреп... .......................
Гыйнвар бураннары *(җыр)* ......................
Сиңа охшаган .................................
Имәнкискә кызына Такталачык егетеннән ачык хат ....
«Ходайга табынам диеп...» ......................
«Син һаман миннән көләсең...» ...................
Айсылукай *(җыр)* ..............................
«Болай булмас чүлдә дә...» .......................
«Мин бит сине тормыштан да...» ..................
Кызыл алма... .................................
Туган көн вальсы *(җыр)* .........................
Гашыйк ......................................
«Карлар ява инде, ап-ак карлар...» ................
Җибәрмим ...................................
«Зәңгәр күкнең упкын-дулкынында...» ...............
«Мартлар булып кердең тормышыма...» ............
«Салкын яңгыр...» ..............................
«Тәрәзә төбендә песнәкләр...» ....................
«Ноябрьләр ахырында...» .......................
Еллар үтәр... .................................
«Синең исемеңнең баш хәрефе...» ................
«Кыш уртасы. Тышта җиләс...» ...................
И Ходам, Мәхәббәт бир! ........................
Ярый, мине кызганма да... .......................
«Мин сине бер көн буена...» ......................
Без икебез бербөтен ............................
Бер җылы сүз... ................................
«Син үзеңнән качасыңмы?..» .....................
«Үлем... Сәер нәрсә...» ..........................
«Өф-өф итеп өрәсең син...» .....................
Җырым бар... ................................
«Күңелемне нурлаучым...» .......................
Бу язларны сиңа бүләк итәм... ...................
«Чык син, кояш...» ..............................
«Кояш кунган күзләреңә...» ......................
Мин сине сагынганмын!.. .......................
«Ишекләр ачыла...» ...........................
Су ташый кыз... ...............................
Иртә яздан мине эзлә син... ......................
«Чык суында юдым битемне...» ...................
Зәңгәр сирин ..................................
«Син киләсең бүген...» ..........................
Синең күзләр .................................
Элегия .......................................

Сагыну җыры ................................
«Синең канны эчкән черки...» .....................
«Чыклы тәрәзләрдән дым бәрә...» .................
«Салкын төнне ярып кайтып киләм...» ..............
«Мин җансыз яшәдем бугай...» ...................
«Җиденче төш күрәсеңдер...» .....................
Сине уйлап... ................................
Әйдә мин көтүче булам... ........................
Тулай торак бүлмәсендәге уйланулар... *(цикл)*
Аяк тавышың ...........................
«Песнәк килгән тәрәз каршыма...» ...........
Дүртенче кат... Бишенче кат... ............
Китәсең дә югаласың... ....................
«Бишенче кат — җиде кат күк...» ...........

**Дүртенче кат**

Айның яктысында .............................
«Хыял иле, хыял диңгезе...» .....................
Күз җыры ...................................
Бәхет кайдадыр?.. .............................
«Тапталган сукмаклар буйлап...» ..................
Шигырь .....................................
Агыйделдә боз китә ............................
«Еллар уза, еллар ага...» ........................
«Чәчләрем дә әз-мәз агаралар...» .................
«Нинди аһәң, нинди көй бу...» ...................
Студент еллары ..............................
Җырла әле ..................................
Моң илчесе булу кирәк .........................
Октябрем ...................................
«Ургып-ургып хисләр ага...» ......................
Кышкы иртә ..................................
Халәт .......................................
Яңгырда .....................................
«Мин сөйләшмим таш диварлар белән...» ..........
«Мин туганмын...» ............................
«Җан — күбәләк...» ............................
«Шигырь белән яшим...» .......................
«Башым тулы миллион идеяләр...» ...............
Сусау .......................................
Яңа ел җыры .................................
Галәм .......................................
Мизгел ......................................
«Мизгелгә күземне йомдым...» ....................
«Кайгы төргән гамьле кичләремдә...» .............
Этюд .......................................
Вакыт .......................................
Күз инде... ...................................
Шундый кеше мин... ............................
«Егермене уздым...» ............................
«Әй, күзкәем...» ...............................
«Яңгыр миңа охшаган...» .......................
«Агачтан төштем мин мәтәлеп...» .................
Соңгы яфрак .................................
«Кар өстендә таплар...» .........................
Ялгызлык ...................................
Иң якын дуска ................................
«Ярым бушлык, ярым караңгылык...» ..............
Илдар абый .................................
«Сәгать саный...» .............................
«Ялган шөһрәт...» ..............................
«Җирдән күккә...» ..............................
«Мин — күкләр малае...» ........................
«Табигатем минем кыр казыдай...» ................
«Гөл коя яфрагын...» ..........................
«Дөньяның өмет ишегең...» ......................
Каурый төште... ..............................
«Шыбыр-шыбыр яуган яңгырда...» ................
Яңгыр .......................................
Җан ........................................
Гомер .......................................
«Күк йөзен куертты бер болыт...» ................
Тупыл мамыгы ................................
«Көн бүген сүрелгән...» ..........................
«Җилле көн...» ................................
«Төнге күккә таш аткан идем...» ..................
«Караңгы...» .................................
«Пип-пип» килеп уйный...» ......................

«Эссе...» ....................................
Мәхәббәт ....................................
Күңел .......................................
«Дөньяда яшеллек...» ..........................
Очам гына ....................................
«Эсселе-суыклы...» ............................
«Чебеннәргә рәхәт...» ..........................
«Ник кысасың, авыртасың, йөрәк...» ..............
«Кара төнне яңгыр юды...» ......................
«Җәй исен исним-исним...» ......................
«Кычкыра тиле дөнья чатында...» ................
Ай ..........................................


**Өченче кат**


«Тарих тулган канлы эзләр белән...» ..............
Дөреслек ....................................
«Кол Шәриф бер...» ............................
Уян, татар!.. ..................................
«Бәхетле илнең баласы...» .......................
Юнәлеш бирү ................................
Сала теле ...................................
Барыбыз да бер гамьле... ........................
Татар моңы ..................................
«Кошлар китә, кошлар кайта...» ...................
«Дала җиле килеп хәбәр бирә...» .................
Үткәннән килгән өн ............................
Татар моңына мәдхия ..........................
Безнең тарих... ...............................
Татарлык ....................................
Казан — Әстерхан поезды .......................
«Бие, бие, бие!» — дисез...» .....................
Тулгак тота мине... ............................
«Керләнгән күңелне...» ..........................
Уфага барганда... .............................
Тарих .......................................
Даһи гомере .................................
Татар яшьләре гимны ...........................


**Икенче кат**


Яшәеш .....................................
Сорап тормады... ..............................
Оялам .......................................
«Син дә сәнгать кешесе лә...» ....................
Юл буйлап килә иркәм ..........................
Бирерләр микән?.. .............................
Мин — кыска, мин — озын ......................
Бар бездә бирәү! .............................
Талант .......................................
Декан буласым килә!.. .........................
Ярты-ярты... Киңәя?! ..........................
Гомер буе шуны аңлатам... .....................
Карлы Маркс урамында... .......................
Без карт идек... ................................
Ходаймы шулай кушкан? .......................
Язышучы ....................................
Миндәй кешегә... ..............................
Гашыйк җан ..................................
Студент монологы ............................
Тигезлек эзләгәндә... ..........................
Әңгәмә ......................................
Бер гомеркәй җитми икән! ......................
Мин сине озак эзләдем... .......................
Юк арды ....................................
Костюм кияргә микән? ..........................
Киңәш ......................................
Күпне белсәм... ...............................
Ярсу ........................................
Шаяртам ....................................
Нишләрмен?.. .................................
Акча әйләнеше... ..............................
«Күбәләккә дусты иркәләнә...» ....................
«Авыздагы кәнфит балы...» ......................
«Такы-токы, гарип юллар...» .......................
«Сандыгында әби кыштыр-кыштыр...» ..............
Үпкәлимен... .................................
«Җәйгә генә аерылдык...» .......................
«Җан җылыңны...» .............................

**Беренче кат**

Нәрсә әйтим? *(Поэма)* ..........................
Йолкынган тамырлар ............................
Гамил Афзалга *(Цикл)*
Җырлы биштәр асып... ..................
Югалган нигез ..........................
Кайтыр... .............................
Кайту ................................

Литературно-художественное издание

***Шаех*** *Ленар*
*(**Шаехов** Ленар Миннемохимович)*

ЭТАЖИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Шәех*** *Ленар*
*(**Шәехов** Ленар Миңнемөһим улы)*

ДҮРТЕНЧЕ КАТ... БИШЕНЧЕ КАТ...

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Р.Н.Нуриева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 3.06.2008. Форматы 70х90 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 6,44. Шартлы буяу-оттиск 6,73. Нәшер-хисап табагы 5,89. Тиражы 2000 экз. Заказ Т-593. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.